УКУЧЫ СҮЗЕ
«ВТ» укучылары хатларында – тормыш кыйпылчыклары

> 4

АККОШЛАР МӘХӘББӘТЕ
Сәгъдиевларга карап: «Сез – бик бәхетле кешеләр», – диләр

> 5

ЮТАЗЫ БАТЫРЫ
Ватан улларын үрнәк итү дә, хәтерләү дә кирәк

> 5

ХА-ХА-ХАНӘ
Кызык-мызык, булмас димә, фототөрткеләр – монда

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 191 (28964) | Шимбә | 24 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ТАРИХ ҖИҢЕЛ ЯЗЫЛМЫЙ

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНДА РЕСПУБЛИКА ҖИТӘКЧЕСЕНЕҢ ЯҢА АТАМАСЫНА БӘЙЛЕ ЗАКОН ПРОЕКТЫН КАБУЛ ИТТЕЛӘР

Рәис! Әмма хәзер үк түгел. Татарстан Дәүләт Советында республика җитәкчесенең яңа атамасына бәйле закон проектын кабул иттеләр. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов федераль үзәк белән яхшы мөнәсәбәтләр турында искәртте. Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев исә моңа карап кына республиканың көче кимемәячәген әйтте.

Татарстан Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышында вакытның күп өлешен көн кадагында торган мәсьәлә алуын әйтеп-аңлатып торасы юк. Билгеле булганча, федераль үзәк таләпләре нигезендә киләсе елдан илдә бер генә Президент калырга тиеш.

– Татарстан югары вазыйфаи заты атамасын «Татарстан Республикасы Башлыгы – Татарстан Республикасы Рәисе» дип атарга тәкъдим итәбез. Аны кыскартып, «Татарстан Рәисе» атамасын куллану мөмкинлеге дә күздә тотыла. Бу, бер яктан, гамәлдәге федераль канунга туры килсә, икенче яктан, Татарстанның тарихи һәм милли үзенчәлекләре исәпкә алыначак. Шул ук вакытта, гамәлдәге Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановны халык сайлап куйганын да истән чыгарырга ярамый. Аңа нәкъ менә Президент буларак тавыш бирделәр. Шуңа күрә республика башлыгының яңа атамасы 2025 елда узасы сайлауда билгеләнәчәк җитәкчегә карата гына кулланыла башлаячак. Бу – халык арасында Татарстан Конституциясенә карата ышанычны саклап калуның бер юлы да булып тора, – диде Дәүләт Советының Дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә комитеты рәисе Альберт Хәбибуллин.

Ул чәршәмбе көнне узган комитет утырышында Татарстан Конституциясенә үзгәрешләр кертүгә бәйле тәкъдимнең депутатлар арасында бәхәс чыгаруын һәм парламентчыларның закон проектын кире алырга тәкъдим итүләрен дә искә төшерде. Альберт Хәбибуллин әйтүенчә, төп бәхәс нәкъ менә Президент атамасы тирәсендә чыккан.

Шуңа күрә Татарстан Дәүләт Советы Президиумы закон проектын сессиянең көн тәртибенә кертте. Бу уңайдан җиде депутат чыгыш ясады. Алар, кайсы тыныч кына үз фикерләрен дәлилләп, кайсы күкрәгенә Татарстан Конституциясен куеп, төрле тәкъдимнәр җиткерде.

– Без болгавыр заманда яшибез. Фикерләрне иләк аша уздырып, сүзне җиде түгел, җитмеш мәртәбә үлчәп сөйли торган заман. Бүген Татарстанда яшәүчеләр өчен генә түгел, бөтен дөнья буйлап сибелгән татар халкы өчен дә тарихи көн. Телибезме-юкмы, тарих ул һәрвакыт алга таба бара. Безгә дә республикабыз киләчәген кайгыртып яшәргә кирәк. Президент атамасы, һичшиксез, тарихи күзлектән каралырга тиеш дип саныйм. Чөнки татар халкының мең елдан артык дәүләтчелек тарихы бар. Бу атама – бүгенге яшәешне шаулы үткәннәр белән бәйли торган бик мөһим фактор. Без тарихи хәтерне һәм дәвамчанлыкны сакларга тиеш. Минем тәкъдимем: татар телендә бу атаманы Татарстан Республикасы Дәүләт Башлыгы дип атарга кирәк, – диде депутат, Татарстан халык артисты Рамил Төхвәтуллин.

Депутат Марат Галиев мәсьәләгә сәяси һәм тарихи күзлектән карарга тәкъдим итте. Аның әйтүенчә, хәзер гамәлдә булган «федераль үзәк белән килешү нигезендәге мөнәсәбәтләр» турында да онытырга ярамый. Марат Галиев Президент атамасын русча ничек тәкъдим ителсә (глава региона. – **Ред.**), шулай калдырып, татарча аны барыбер Татарстан Президенты дип йөртергә тәкъдим итте.

Депутат, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов трибунадан Тукай шигырен дә сөйләп күрсәтте хәтта.

– Мин бүген үземнән сорыйм: «Миндә тычкан утыдай нур калдымы?» Калды, дип саныйм. Һәм калырга да тиеш. Чөнки минем йөрәгемдә Татарстан Конституциясе бар. Әйе, сәясәтчеләр гел: «Сәясәт ул – үзара килешүгә килә алу осталыгы», – диләр. Акыл белән аңлыйм, әмма кызганыч, йөрәгем белән кабул итә алмыйм. Шәхсән минем өчен бу мәсьәләдә уртаклыкка килү мөмкин түгел. Үзара килешүләр күп булды инде. Бу – Шартнамә дә, тел мәсьәләсе дә, Конституция суды да. Әмма бүген үзгә хәл. Конституция кәгазь кисәге генә түгел, ул – халык теләге. Президентны да алар сайлап куя. Мин үз халкыма каршы бара аламмы? Юк! – диде ул һәм бу мәсьәләдә йөрәге кушканча тавыш бирәчәген әйтте.

Коммунист Хафиз Миргалимов исә, исеменнән бигрәк җисеменә игътибар итәргә кирәк, дигән фикердә.

– «Президент» сүзе бөтен яктан да безнең республикага туры килә. Мөмкин булса, аны калдыру яклы тавыш бирер идем. Тик киләчәккә карап эш итәргә кирәк. «Рәис» тә – бик көчле сүз, – диде ул.

Бу фикер белән Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Радик Салихов та килешә. Аның әйтүенчә, Татарстанның беренче җитәкчеләрен дә «Рәис» дип атаганнар.

– Совет Татарстанын оештыручыларның берсе һәм Халык комиссарлары советының беренче рәисе Сәхипгәрәй Сәетгалиев «Татарстан Республикасы Рәисе» дип аталган. Аның дәвамчысы – ТАССР Совнаркомы рәисе вазыйфасындагы Кәшшаф Мохтаров рәсми рәвештә «Рәис» дип аталган. Ул тарихи яктан мантыйкка туры килә. Шулай ук республиканың чит ил партнерлары өчен дә аңлашыла, һәм «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркемен җитәкләүче Рөстәм Миңнехановның халыкара эшчәнлеге контекстында сөйләсәк, бу сүз гарәп дөньясына бик яхшы аңлашыла, дәүләт җитәкчесе белән эш итүләрен аңлаячаклар, – дигән ул «Татар-информ» хәбәрчесенә.

Сессиягә әйләнеп кайтсак, утырышта Президент Рөстәм Миңнеханов та сүз алды һәм мөһим мәсьәләгә карата үз фикерен җиткерде.

– Бу – барыбыз өчен дә авырткан җир, әмма безгә алга барырга, бу мәсьәләгә бәйле карар кабул итәргә кирәк, – диде Президент. Залда утыручыларның хәленә керергә тырышып: «Сезне бик яхшы аңлыйм. Сезнең урында булсам...» – дип, бер мәлгә тынып та калды. Аннары сүзен дәвам иттерде.

Ахыры 2 нче биттә >

Өстәмә түләү булмый

Яңа елга балалы гаиләләргә өстәмә түләүләр күздә тотылмый. Россия хезмәт һәм социаль яклау министры Антон Котяков әйтүенчә, 1 гыйнвардан мондый гаиләләргә ярдәм итү җәһәтеннән үзгәреш булачак – бердәм пособие гамәлгә кертелә. Министр сүзләренә караганда, әлегә шуның буенча эш алып барыла.

Моңа кадәр Федерация Советында киләсе елдан бала тудыру һәм тәрбияләүгә бәйле бердәм пособие билгеләүне күздә тоткан закон хупланды. Документ нигезендә, 17 яшькә кадәрге балаларга, шулай ук йөкле хатын-кызларга ай саен универсаль пособие биреләчәк.

Кыш бабайдан көтәләр

Белгечләр, Татарстанда яшәүчеләр арасында сораштыру үткәреп, эш-карьера мәсьәләсендә Кыш бабайдан ниндирәк бүләк көтүләрен ачыклаган.

Респондентларның күбесе – 32 проценты хезмәт хакы артуны тели. Бигрәк тә төзүчеләр, транспорт һәм логистика хезмәткәрләре, кадрлар бүлегендә эшләүчеләр. 19 проценты яңа һөнәр үзләштерергә хыяллана. Аеруча IT өлкәсендә эшләргә хыялланучылар күп (25%). 6% – маркетинг, 9% – сәнгать, 16% – финанс, 6% – медицина, 9% юрист һөнәрен үзләштермәкче.

Сораштыруда катнашучыларның 22 проценты Кыш бабайга һөнәри осталыгын үстерүне, 5 проценты – белгеч буларак танылуны, 14 проценты – өстәмә һөнәргә өйрәнүне, 3 проценты вазыйфасында үсү теләген җиткерүне күздә тота.

«Киләсе елда һөнәрне нәрсәгә карап сайлап алыр идегез?» дигән сорауга, респондентларның 57 проценты – хезмәт хакы күләменә, 49 проценты – тотрыклылык, 41 проценты – эштә үсү мөмкинлегенә, 46 проценты, һөнәрнең ни дәрәҗәдә кирәкле булуына карап, дип җавап биргән.

Шаярып сөйләшмә

Юрист ни өчен телефон мошенниклары белән шаярып сөйләшергә ярамавын аңлаткан. Россиянең атказанган юристы Иван Соловьев әйтүенчә, кайберәүләребез, шалтыратучының мошенник икәненә төшенеп, төртмә сүзләр белән шаярта башлый. Әмма бу – куркыныч гамәл. Мондый очракта аферист төрлечә янарга мөмкин. Ул гына да түгел – кайбер үткен телледәрне, соңыннан үч алу өчен, «кара исемлек»кә кертү очраклары да булгалый. Ә үч алуда, әлбәттә инде, төрле алдау алымнары кулланыла.

Белгеч әйтүенчә, шаяртып сөйләшүченең телефон номеры, ахыр чиктә, мошенникларның полициягә язган гаризасына эләгергә мөмкин. Шуңа күрә юрист, шалтыратучының кем икәнлеген аңлап алуга, трубканы куярга киңәш итә.

Актуаль мәсьәлә

Битлекне саласы түгел

Татарстанда коронавирус чорындагы кебек битлек режимын кайтарырга җыенмыйлар. Киләчәктә нәрсә булачагы исә халыкның яңарак кына кертелгән чикләүләрне ни дәрәҗәдә төгәл үтәвенә бәйле. Роспотребнадзорның Татарстан идарәсе башлыгы Любовь Авдонина шулай дип белдерде.

Билгеле булганча, узган атнада Татарстанда социаль һәм медицина оешмаларында мәҗбүри рәвештә битлек кию тәртибе кертелде.

Белгечләр декабрь азагы – гыйнвар башында вируслы чирләр белән авыручылар санының бермә-бер артачагын фаразлый.

– Бар да безнең яңарак кына кертелгән чикләүләрне ни дәрәҗәдә үтәвебездән тора. Декабрь азагы – гыйнвар башында авыручылар саны зур булыр әле. Бу аңлашыла да: тиздән озын Яңа ел яллары башланачак. Безнең халык исә бик актив. Башка төбәкләргә, илләргә дә чыгачаклар, туганнар белән күрешеп, кунакларга да йөрешәчәкләр. Бездә массакүләм чаралар үткәрү тыелмаган. Шуңа күрә бәйрәм ялларында авыручылар саны да югары дәрәҗәдә сакланыр, дип фаразлыйбыз, – ди Авдонина.

Белгечләр бәйрәм чорында да сәламәтлек турында онытмаска: кеше күп җыелган, ябык биналарда озак тормаска, күбрәк саф һавада йөрергә, спорт белән шөгыльләнергә киңәш итә. Битлекне дә үзеңнән калдырасы түгел.

Бүген республикада ОРВИ һәм грипп белән авыручылар саны кискен арткан. Бер атна эчендә Татарстанда ОРВИ һәм грипп йоктыруның 40759 очрагы теркәлгән. Шуларның 413е гриппка туры килә. Бу алдагы атна белән чагыштырганда 41 процентка күбрәк. Шул рәвешле республикада авыручылар саны эпидемик чиктән ике тапкыр югарырак. Авдонина сүзләренә караганда, республика халкы арасында дуңгыз гриппы йоктыручылар да шактый. Грипп очракларының 82 проценты шуңа туры килә.

Бер атна эчендә Татарстанда коронавирус йоктыру очраклары да 15 процентка арткан. Әмма белгечләр моны әллә ни куркыныч сан түгел, дип әйтә.

– Ковидка бәйле вазгыять тотрыклы. Әлеге инфекция көндәлек тормышыбызның бер өлешенә әйләнде инде. Хәзерге вакытта хастаханәләрдә ятак урыннар саны җитәрлек. Аларның 5 проценты буш. Коронавируслы вазгыять катлаулана калса, аларның санын арттырачакбыз. Бу проблема түгел. Өч ел эчендә без бу эшне оператив рәвештә оештырырга өйрәнеп беттек инде, – ди Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары, Казанның Сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы Владимир Жаворонков.

Коронавируска каршы вакцина ясау пунктларының штатлы рәвештә эшләвен, вакцинаның җитәрлек булуын да искәртте ул.

– Балаларга ясала торган вакцина да җитәрлек. Бу урында тагын бер кат искәртәсем килә: вакцинаны теләге булган кешегә генә ясыйбыз, – дип ассызыклап әйтте Жаворонков.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Михаил МУРАШКО, Россия сәламәтлек саклау министры:

Яңа ел бәйрәмнәре чорында сәламәтлек саклау системасының эшен көчәйтергә кирәк. Яңа ел каникулында халык диспансеризация уза алсын, даруханә пунктларына, травмпунктларга мөрәҗәгать итсен һәм кирәкле ярдәм алсын өчен, медицина оешмаларының эш графигын дөрес итеп формалаштыру зарур.

(Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы матбугат хезмәте)

РОССИЯДӘ – ХЕЗМӘТТӘШЛӘР БЕЛӘН МӨНӘСӘБӘТ

«Битрикс24» бизнес белән идарә итү онлайн хезмәте хезмәт коллективларындагы мөнәсәбәтләр турында сораштыру оештырган. Коллегалары белән яхшы мөнәсәбәттә булулары турында сораштыруда катнашучыларның 63 проценты әйткән.

69% >> бергә төшке аш ашый

41% >> серләре белән уртаклаша

31% >> кунакка йөрешә

Карлы-буранлы ай

Кыш җиткәннән бирле Казан урамнарыннан 311 мең тонна кар чыгарылган инде. Казан Башкарма комитеты җитәкчесе Рөстәм Гафаров әйтүенчә, узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда 3 тапкыр күбрәк бу.

Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, 1 декабрьдән бирле республика башкаласында 60,5 мм күләмендә явым-төшем булган (айлык норманың 121 проценты). Барлыгы 206 мең тонна кар – эретү пунктларына, 105 мең тоннасы өемнәргә озатылган. Узган ел шушы ук чорда Казан урамнарыннан 108 мең тонна кар чыгарылган булган.

Рөстәм Гафаров район хакимиятләре башлыклары белән очрашуда шәһәр юлларын җыештыруга җаваплы оешмаларның эшен тәнкыйтьләгән. Ул тротуарлар, җәяүлеләр сукмаклары, тукталыш тирәләре каралмауга игътибар иткән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Исеме түгел, җисеме

Татарстан Конституциясенә төзәтмәләр кертү турында 23 декабрьдә Татарстан Дәүләт Советының депутатлар төркеме әзерләгән канун проектының язмышы, ниһаять, парламентта хәл ителде: Татарстан җитәкчесе Президент дип түгел, Рәис дип атап йөртеләчәк. Ләкин киләсе сайлаудан соң гына.

Россиянең мәгълүмат кырында безнең республиканың бердәнбер президентлы төбәк булып калуы тирәсендә канәгатьсезлек чыгышлары күптәннән һәм еш яңгырый иде. Быелның җәендә генә дә аны «РИА Новости» агентлыгы, рус телле «Форбс», россиякүләм башка мәгълүмат чаралары төрләндергән. «Президент» атамасын Татарстанда да, Федераль үзәктә дә республиканың мөстәкыйльлеге символы итеп таныйлар, бу сер түгел.

Төбәк җитәкчеләреннән бу исемне алу, аларны я башлык, я губернатор дип кенә атау хәрәкәте 2010 елда ук Рамзан Кадыров инициативасы белән башланган иде. Башка милли республикалар үз җитәкчеләрен башлык дип атауга тиз күчтеләр. Бары тик Казан гына Мәскәү белән конфронтациягә кермичә, бәхәс чыгармыйча, атаманы әлегә кадәр саклап килде. Мәскәү Кремлендә дә яхшы аңлыйлар: Татарстан үзенең сәнәгать потенциалы белән дә, фәнни-техник куәте белән дә, финанс системасының тотрыклылыгы ягыннан да, даими үсеш сукмагыннан баруы белән дә Россиянең башка төбәкләреннән җитди аерылып тора. Бездә электән, совет чорыннан калган потенциал да көчле иде.

Татарстан җитәкчелеге шул потенциалны саклау һәм үстерү өчен аз тырышмады. Гомум ил күләмендәге җимереклек һәм таркалу фонында моны эшләү җиңел булмады, әлбәттә. Өзелгән элемтәләр урынына яңаларын булдыру, хезмәттәшлекнең башка мәйданнарын ачу һәм киңәйтү таләп ителә. Лидерга күп йөрергә, чит илләргә визитлар белән барырга, зур дәүләтләрнең җитәкчеләре белән өстәл янында кара-каршы утырып сөйләшергә туры килә. Лидерның статусы югары булу мәсьәләне хәл итмәсә дә, барыбер булыша. Татарстан җитәкчелеге исә дипломатик сөйләшүләр алып бару талантына ия, кайвакыт хәтта федераль дипломатия өчен ябык булган ишекләрне дә ача алу сәләтен күрсәтә иде.

Дөресен генә әйткәндә, сөйләшүләр алып бару осталыгы буенча Казан Мәскәүгә мастер-класс күрсәтә алырлык югарылыкта торды һәрвакыт. Шундый югарылык булмаса, федераль үзәк бары тик Татарстанда гына Президент атамасының унике елга якын сакланып калуына түзмәс иде. Бу асылда тиңлек, тигезлек билгесенә якын бит. Рус милли хәрәкәте аны нәкъ менә шулай аңлый да, шуңа күрә ул күп кенә көчләрнең кытыгына тия. Мәскәү Кремлендә моны исәпкә алмый кала алмыйлар. Вазгыятьнең нинди икәнен күреп торабыз бит: ул бензин мичкәсе янында шырпы кабызган шикелле. Телеграм-каналларда да яхшы күренә ул. Соңгы көннәрдә Татарстан Президенты атамасы мәсьәләсе хәтта уртачыл карашлы популяр каналларда да бик кыздырылды, аны конфронтация дәрәҗәсенә күтәрергә тырышучылар күп булды. Бүгенге вазгыятьтә исә конфронтация түгел, компромисслар отышлырак. Дәүләт Советында тикшерелгән канун проектын мин шулай аңлыйм, мәсәлән.

Чынлыкта эш атамада түгел. Атаманың символ буларак роле бар, билгеле, әмма хәлиткеч түгел. Рөстәм Миңнехановның Катарга соңгы баруын гына алыйк. Илнең иң югары җитәкчесе, хәрби көчләр башкомандующие әмир Тәмим бин Хәмәд Аль Тани, Татарстан лидеры кем дип кенә аталмасын, аның белән барыбер тиң күреп сөйләшәчәк иде. Ә бит ул сөйләшүләрдә «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме кысасында хезмәттәшлек мәсьәләләре тикшерелде. Масштабның зурлыгы гына түгел, санкцияләр чолганышында калган Россия өчен (ассызыклыйк, Татарстан өчен генә түгел) хәлиткеч әһәмиятле булуы хакында бара монда сүз.

Сер түгел: Татарстан Россия өчен Урта Азия республикалары, төрки һәм ислам дөньясы арасында күпер ролен уйный. Шул зур географик киңлекләрне иңләп торган, куәтле потенциалга ия булган дөньяның кайсы гына иленә барса да, Татарстан лидерын ул дәүләтләрнең югары җитәкчелеге тиң күреп кабул итә. Әйтик, быел ноябрь ахырында Азәрбайҗанга визиты вакытында Президент Илһам Алиев та, премьер-министр да Миңнеханов белән тигез күреп сөйләшүләр алып бардылар. Татарстан – Азәрбайҗан хезмәттәшлеге исә быел кызу үсештә. Үткән ел сәүдә әйләнеше 70 миллион долларлык булса, быелның беренче яртысында ук инде 60 миллионга җиткән һәм берничә тапкыр артырга вәгъдә итә. Шундый ук хәл Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан һәм башка дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрдә дә күзәтелә. Татарстан Президенты иң югары дәрәҗәдә сөйләшүләр алып бара һәм… ул сөйләшүләр Россия мәнфәгатьләренә хезмәт итә. Дөресен генә әйткәндә, СССР таркалганнан соң килеп туган таркаулык Урта Азия республикаларындагы сәнәгатьне дә җимереп ташлаган, белгечләр юкка чыккан. Бу бигрәк тә авиация кебек зур инвестицияләр сорый торган тармакларга карый. Хәзер менә шуларны бергәләп торгызырга туры килә. Мәскәү моны Татарстаннан башка эшли алмый. Бердән, төп сәнәгать потенциалы бездә һәм ул, бәхеткә, җимерелеп үк бетмәгән. Икенчедән, рухи элемтәләр дә үз сүзен әйтә.

Президент атамасына килсәк, болайрак бит инде: латин сүзе «алда утыручы, рәис» дигәнне аңлата һәм лидерлары сайланып куела торган дәүләтләрдә кулланыла. Төрле оешма, компанияләрнең җитәкчеләрен дә «президент» дип атау традициясе бар. Туксанынчы елларда балалар оешмаларына кадәр үзләренә президентлар һәм вице-президентлар сайлап бетерделәр. Күрәбез: атаманың үзенең генә аерым бер куәте юк, эш исемдә түгел, җисемдә. Россия чит атамаларны үз җитәкчеләренә кабул итеп, символик яктан үз суверенитетын чикләгән асылда. Гарәпләр кулланмый ул сүзне. Алар рәис Байден, рәис Путин дип сөйлиләр. Ышанмасагыз, «Әл-Җәзира»ны карагыз. Шулай булгач, Татарстан Президентын Рәис дип атау – иң отышлы юл, Президент түгел, әмма шундый ук мәгънәви куәткә ия. Безнең колакка да ятышлы.

ТАРИХ ҖИҢЕЛ ЯЗЫЛМЫЙ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Президент атамасына килгәндә, без күчереп булган әйберләрне күчерә килдек. Ике срок рәттән республика Президентын сайлый алуыбыз да – федераль үзәкнең республикага карата мөнәсәбәте. Безгә каршы чыгучылар да булды. Әмма без, республика җитәкчесенең атамасын саклап калу өчен, бу эшне дәвам иттердек. Президент атамасын саклап калып булмаячагын аңлый башлагач кына, башка юллар эзләүгә керештек. Бәлки, минем дә, депутатларыбызның да тырышлыгы җитәрлек булмагандыр. Кызганыч, без атаманы билгеләү хокукын үзебездә саклап кала алмадык. Тик бу ишек ябылып бетмәгән бит әле, алга таба ничек тә үз хокукларыбызны якларга тырышырбыз, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Кирегә юл юклыгын искәртеп, нинди дә булса уртак фикергә килергә кирәклеген дә әйтте.

– Бүген яңгыраган тәкъдимнәр идеаль түгел, әмма ул алга таба хәрәкәт итәргә этәргеч бирә. Һәрвакытта да без теләгәнчә булып бетми. Битараф булсак, бик күпкә начар булыр иде. Сезнең борчылуыгыз, сайлаучыларыгызның фикерен ирештерүегез – уңай күренеш. Әмма сез аңларга тиеш: Татарстан – илнең барлык тармаклары буенча да нык төбәкләренең берсе. Ничек кенә булмасын, килешү үз өлешен кертте. Без бүген барлык федераль проектларда катнашабыз. Ил җитәкчелеге, хөкүмәт белән мөнәсәбәтләребез бик яхшы. Төп максат нәрсәдән гыйбарәт? Без халыкның тормыш дәрәҗәсен яхшыртырга тиеш. Шулай эшлибез дә. Әйе, без – федераль үзәккә иң күп салым озатучыларның берсе. Әмма республика оешма-предприятиеләре ярдәмне дә күп ала. Федераль үзәк белән хәзерге мөнәсәбәтләребез бик әһәмиятле. Мин моңарчы бервакытта да сезнең эшегезгә кысылмадым, сорамадым. Әмма бүген сүз Татарстан Президенты буларак миңа карата булган ышаныч турында бара. Уңай карар кабул итә алмасак, әйбәт булмаячак, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Аннары трибунага Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев чыкты һәм соңгы сүзне әйтте. Бу аңлашыла да. Аның фикере хөрмәт ителә, Минтимер Шәймиевкә бездә генә түгел, Татарстаннан читтә дә колак салалар. Дәүләт Киңәшчесе фикеренчә, тарих бервакытта да җиңел язылмаган. 2000 нче елларда Президент атамасы тирәсендә булган катлаулы фикер алышуларны да искә төшерде ул.

– Әмма бүген илнең бердәмлеге төп бурыч булып тора. Махсус хәрби операция алып барылуын, Россия составына яңа субъектлар, шул исәптән ике зур төбәк – Донецк һәм Луганск республикалары кертелүен истән чыгарырга ярамый. Депутатларның тәкъдимен хуплыйм. Рәис атамасы бик яхшы. Рөстәм Миңнехановның вәкаләтләре чыкканчы, Президент атамасы сакланып калу да мөһим. Чөнки аны халык сайлап куйды. Бүген яңа сайлаулар үткәрү яки референдум оештыру өчен вакыты ул түгел. Без федераль үзәк белән уртак тел табарга тиеш. Ә халык һәм җитәкчелекнең бердәмлеге, ярдәме Россия Президентына да бик кирәк. Бу үзгәрешләрдән Татарстанның көче кимемәячәк, – диде Минтимер Шәймиев.

Фикер алышудан соң, закон проектын беренче укылышта кабул итүне яклап, 78 депутат тавыш бирде, икесе каршы чыкты. Тәнәфестән соң Татарстан Конституциясенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан закон проектын үзгәрешләрсез икенче һәм өченче укылышта кабул иттеләр. Анда төбәк җитәкчесе вазыйфасының яңа атамасы – «Татарстан Республикасы Башлыгы – Рәисе» дип тәкъдим ителгән.

Сессиядә көн тәртибендәге башка мәсьәләләр дә каралды. Шул исәптән 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджет турында республика законына үзгәрешләр кертү хакында закон проекты беренче укылышта һәм тулаем кабул ителде.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Фикер

Зилә ВӘЛИЕВА,
Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе:

– «Рәис» сүзе башка телдән алынса да, иң югары дәрәҗәдәге вазыйфаи затны билгеләр өчен кулланылган. Гасыр башында Сәхипгәрәй Сәетгалиевның вазыйфасы да «ТАССР Халык комиссарлары советының беренче рәисе» дип аталган. Аннан соң килгән кешене дә шулай атаганнар. Шуңа күрә мин моны татар сүзе буларак кабул итәм һәм Конституциягә дә шулай кабул ителә.

Монда сүз атама турында гына бармый. «Татарстан Республикасы Президенты» – соңгы елларда республикадагы иң югары дәрәҗәдәге вазыйфаи зат. Бу сүзнең авторитетка, хөрмәткә ия булуында ике шәхеснең әйтеп бетергесез зур хезмәте тора. Россия, дөнья масштабларындагы тырышлыклары гаять зур. Һәм ул хезмәтләр республика иминлеге өчен генә эшләнмәде. Моңа инаныр өчен, быел Рөстәм Миңнехановның сәфәрләренә игътибар итү дә җитә. Ишекләр ябылса да, аның халыкара эш сәфәрләре Татарстан, Россия өчен дуслар, партнерлар эзләүгә бәйле иде. Шуңа күрә хәзер иң мөһиме – «Рәис» сүзенең дә шундый эчтәлеккә ия, республика эшләрендә шундый ук позицияләргә бәйле булуы. Республика статусы да җитәкчеләребез, оешмалар, предприятиеләр һәм, иң мөһиме, безнең гражданнар эше белән тулылансын иде. Һәм бу дәрәҗәне чыннан да төшермәскә кирәк.

Анастасия ИСАЕВА,
Татарстан Иҗтимагый палатасы әгъзасы:

– Депутатлар – республикада яшәүчеләрнең фикерен җиткерүчеләр дә. Шундый тәкъдим кергән икән, бу җентекләп уйланылган, димәк. Махсус хәрби операция шартларында басым хакимиятнең бердәмлек принцибына ясала һәм республика җитәкчелеге моны яхшы аңлый. Республиканың иң югары вазыйфаи затының атамасын үзгәртү – һичшиксез, көчле карар да, тышкы күзәтүчеләр өчен үзенә күрә бер сигнал да. Без исә барыбызның да федераль үзәк һәм лидерыбыз тирәсендә берләшүебезне күрсәттек.

Татарстан күп кенә тармаклар буенча лидер төбәк санала. Республикабыз Россиянең терәк төбәге булып тора. Күп кенә тармаклар үсешенә өлеш кертә. Әйтик, дәүләтчелекне, оборона-саклану өлкәләре, дисеңме. Әлбәттә, иң элек моның нигезендә система һәм дәүләт органнарының уңышлы корылган эше ята. Шуңа да, бу шартларда республиканы кем җитәкләве һәм аның ничек эшләве әһәмиятлерәк. Рөстәм Нургали улының исә авторитеты бернинди шик тудырмый.

БИРЕШЕРГӘ ИСӘП ЮК

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ БЫЕЛГЫ ЭШЕНӘ ЙОМГАК ЯСАДЫ

– Бүген без чиктән тыш катлаулы шартларда – махсус хәрби операция һәм глобаль санкцияләр басымы астында яшибез, – дип башлады үзенең чыгышын Фәрит Мөхәммәтшин. – Республикада икътисадны яңа шартларга көйләү дәвам итә, продукция, комплектлау детальләре китерү-җибәрү өчен яңа юллар салына, импортны алыштыру производстволарын булдыру, хезмәт урыннарын саклау буенча эш бара. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның даими игътибары, федераль үзәк ярдәме нәтиҗәсендә хакимият органнары белән бизнес бер йодрыкка тупланып эшли башлады, республика икътисады моңарчы күрелмәгән кыенлыкларга бирешмәвен күрсәтә.

Парламент эше йомгакларына килгәндә, Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, быел 11 утырыш уздырылып, барлыгы 234 мәсьәлә каралган. Шуның 200дән артыграгы (85 проценты чамасы) – социаль юнәлешле мәсьәлә. Законнар чыгаруга, закон проекты эшчәнлегендә катнашучылар даирәсен киңәйтүгә парламент комитетлары каршындагы Экспертлар советлары зур өлеш кертеп килә. Алар, 2022 елда 67 утырыш үткәреп, 245 мәсьәлә караган. Дәүләт Советы 93 закон кабул иткән.

Татарстан Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында закон проекты, һичшиксез, җәмгыятьтә зур ыгы-зыгы һәм кызу бәхәсләр тудырды. «Эмоцияләр аңлашыла, әмма федераль үзәк шундый карар кабул итте, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Төбәк законнарын «Гавами хакимиятне оештыру турында» федераль законга туры китерүгә бик җитди карадык, ведомствоара комиссия зур эш башкарды».

Фәрит Мөхәммәтшин быел парламент кабул иткән мөһим законнар арасыннан «2023 елга һәм планда каралган 2024, 2025 елларга республика бюджеты турында» законны атап үтте. Дәүләт Советы Рәисе билгеләп үткәнчә, төп финанс документының югары дәрәҗәдә социаль юнәлешле булуы (чыгымнарның 80 проценты чамасы шуңа туры килә) сакланып калган. Бюджетка, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән килештереп, соңгы сайлау кампанияләре барышында тупланган наказларны үтәүгә чыгымнар кертелгән.

«Киләсе ел да социаль-икътисадый, шулай ук сәяси яктан җиңелрәк булмас кебек, – дип басым ясап әйтте Фәрит Мөхәммәтшин чыгышы ахырында. – Шуңа да карамастан, халкыбызның ил Президенты Владимир Путин тирәсендә тупланганлыгын, бердәмлеген саклап калу, республика Президенты Рөстәм Миңнеханов тирәсендә тагын да ныграк берләшү, намуслы эшләү, үз бурычларыңны үтәүгә җаваплы карау кирәк».

tatarstan.ru

Татарстан Дәүләт Советында Россия күләмендә уза торган «Теләкләр чыршысы» хәйрия акциясе үтте. Әлеге игелекле чарада Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, республиканың Премьер-министры Алексей Песошин, парламент депутатлары һәм министрлар да катнашты. Парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Нурлат районында яшәүче Даниэльнең теләген чынга ашырачак. Аның бик тә тимер юл составы белән идарә итәсе килә.

Фәрит Мөхәммәтшин киләсе елга бурычларга тукталып, Дәүләт Советының Үрнәк планына инде 29 закон проекты кертелүен билгеләп үтте. «Алга таба да икътисадның тотрыклылыгын үстерүгә, кешеләребезнең социаль якланылышын, авылда яшәүчеләрнең эшмәкәрлек активлыгын үстерүгә ярдәм итәчәкбез, – диде парламент башлыгы. – Илкүләм проектларны, республика планнары һәм программаларын тормышка ашыру да өстенлекле бурычларыбыз булып тора. Боларның барысы да Президентның республика Дәүләт Советына Юлламасында, шулай ук Стратегия-2030 документында урын алган».

Табигатьне дә кайгыртасы

Якын киләчәктә Татарстан районнарында яңа сәнәгать парклары, туризм объектлары пәйда булачак. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында узган Инвестицион совет утырышында шундый инвестиция проектлары каралды һәм расланды.

Алар тәкъдим иткән проектлар исә күпкырлы. Әйтик, утырышта Казанның Сәлимҗанов урамында «Газпром трансгаз Казан» административ комплекс төзелеше» проекты тәкъдим ителде. Әлеге объект өч манара, күпкатлы җир асты машина кую урыныннан торачак. Биредә кулланучылар өчен заманча абонент пункты да урнашачак.

Инвесторлар сәламәтлек саклауга юнәлтелгән инвестицион проектларны да тормышка ашырмакчы. Мисал өчен, башкаладагы «Инсайт» клиникасы каршында дәвалау-тернәкләндерү комплексы төзү планлаштырыла. Биредә наркология һәм психиатрия оешмаларында стационар дәваланган кешеләр тернәкләнә алачак. Әлеге проектны тормышка ашыру өчен 60 миллион сум акча сарыф итеп, 20–30 яңа эш урыны булдырмакчылар.

Чаллыда ачылачак күпфункцияле медицина үзәгендә дә 87 эш урыны булачак дип ышандыралар. Түбән Камада спорт сөючеләр өчен «ФИЗРА спорт үзәге» физкультура-тернәкләндерү комплексы төземәкчеләр.

Инвестицион совет утырышында башка тармакка караган кызыклы проектлар да тәкъдим ителде. Актаныш районында «Актаныш сәнәгать паркы» инвестиция проектын тормышка ашыруны хуплаганнар. Алексеевск районында да җирле сәнәгать паркы проекты каралган.

Утырышта Казан һәм Яшел Үзәндә законсыз рәвештә кулланылган карьерларны торгызу проекты да тәкъдим ителде. Әлеге проект кысасында төзелеш һәм ремонт калдыкларын кабул итү өчен 2 мәйданчык булдыру күздә тотыла.

Туризм тармагында да яңалыклар көтелә. Татарстанның туризм буенча дәүләт комитеты рәисе Сергей Иванов сүзләренә караганда, якын киләчәктә Бөгелмә районында «Карабаш диңгезе» дип исемләнгән курорт төзергә җыеналар. Биредә 50 номердан торган кунакханә, 20 кунак йорты, тау чаңгысы комплексы, ресторан эшләячәк. Утырышта «Ак Лилия» глэмпинг-паркы, «Җилкәннәр» глемпингы һәм «Кечкенә Якутия» туристик этнокомплексы проектлары турында да сөйләделәр.

Алда телгә алынган барлык проектлар да Инвестицион совет әгъзалары тарафыннан хупланды. Рөстәм Миңнеханов әлеге проектларга ихтыяҗның зур булуын искәртте. Ул аларны тормышка ашыру мәсьәләләрен җентекләп өйрәнергә кушты. «Әлеге туризм һәм рекреация объектларының кыйммәте – аларның табигый үзенчәлегендә. Барлык экологик таләпләрне үтәп, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметергә кирәк», – диде Президент.

ЭТ ЭТЛЕГЕН ИТӘР

Борчыган мәсьәлә

Сукбай этләргә кагылышлы күңелсез хәбәрләрнең тынып торганы юк. Әле бер, әле икенче җирдә кешеләргә ташланган яки өер-өер булып йөргән хайваннар турында ишетеп торабыз.

Әйтик, Казанның Борисоглебск бистәсендә яшәүчеләрне дә бер төркем сукбай этләр куркытып тота. Биредәге халык сүзләре буенча, кимендә унлап эттән торган төркемне тукталыш, кибет, мәктәп тирәләрендә очратырга мөмкин.

– Без Ленин урамында яшибез. Сукбай этләр бездә һәрвакыт булды. Ә соңгы көннәрдә алар тагын да артты. Төнлә дә, көндез дә очратырга мөмкин аларны. Балаларны урамга чыгарып җибәрергә куркыныч. Һәрвакыт мәктәпкә озатып, каршы алып та булмый бит, – ди Галина Смирнова.

Роспотребнадзор мәгълүматлары буенча, быел тугыз айда Россиядә этләр һөҗүменнән 142 мең кеше зыян күргән. Билгеле, сукбай этләр проблемасы бер бүген генә баш калкытмаган. Проблеманың тамырына балта чабардай конкрет чаралар күрелмәсә дә, соңгы ике айда аларга кагылышлы берничә закон проекты Дәүләт Думасына кертелде. Тик әлегә алар проект дәрәҗәсендә генә кала бирә.

Соңгы вакытта хайваннарга тамга салудагы үзгәрешләр игътибар үзәгендә булды. Билгеле булганча, 2024 елның 1 мартыннан барлык төр авыл хуҗалыгы терлекләрен тәңгәлләштерә башлыйлар. Әлегә йорт хайваннарын – эт һәм мәчеләрне – мәҗбүри тамгаламаячаклар. Тик киләчәктә бу исемлеккә аларны да кертмәкчеләр. Россельхознадзорның Иҗтимагый советы экспертлары фикеренчә, тамгалау җавапсыз хуҗаларны ачыкларга да ярдәм итәчәк.

Казан ветеринария берләшмәсенең дәвалау-профилактика буенча баш ветеринария табибы Гали Исхаков фикеренчә, сукбай этләр өчен кайчандыр аларны җылы йортларына алып кайтып, соңыннан кирәксезгә чыгарган хуҗалары гаепле.

– Күпләр этләргә җавапсыз карый, – ди ул. – Урамга чыгарып аткан яки теркәтмәгән өчен барыбер берни дә булмый, дип уйлый. Бу – бик зур җавапсызлык. Андый кешеләр өчен эт – дус түгел, ә уенчык. «Ватылса», чыгарып ташлап, яңаны алалар. Миңа калса, мондый кешеләргә закон катгый булырга тиеш: алгансың икән – теркәт! Теркәтмәгәнсең икән, штраф түлә. Чит илләрдә куркыныч токымлы эт алган кешеләргә бик күп таләпләр куялар. Һәм алар, бу адымга барганчы, мең кат уйлый. Бездә исә берни дә юк.

Штраф дигәннән, этләрен борынчыксыз һәм баусыз йөрткән өчен Россиядә яңа штраф билгеләү тәкъдиме белән ЛДПР депутатлары чыккан. Дәүләт Думасына кертелгән закон проектының эчтәлегеннән аңлашылганча, депутатлар кешеләргә куркыныч тудырырга мөмкин булган токымлы этләрне борынчыксыз һәм баусыз урамга алып чыккан өчен 1 меңнән 3 мең сумга кадәр штраф түләттерергә тәкъдим итә. Әлеге исемлеккә 12 эт токымы керә.

Бу тәкъдим белән чыгучылар сүзләренчә, әлеге вакытта Россиядә куркыныч токымлы этләрне борынчыксыз һәм баусыз йөрткән өчен штраф аерым бер субъектларда гына каралган. Анысы да җирле законнар дәрәҗәсендә генә. Ә менә федераль һәм төбәкләр дәрәҗәсендә мәсьәлә күтәрелмәгән.

ЛДПР фракциясе җитәкчесенең беренче урынбасары Сергей Леонов фикеренчә, бу чара ярдәм итәр иде.

– Без көн саен шундый күңелсез хәбәрләр турында ишетәбез. Кемнедер эт тешләгән, кемгәдер зур зыян салган яки ишегалдындагы песиләргә ташланганнар. Халык һаман зарлана һәм безнең берәр чара күрүебезне сорый, – дигән Сергей Леонов.

Россия Кинология федерациясе хәбәр иткәнчә, россиялеләрнең күпчелеге зур булмаган эт токымнарын сайлый.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Эт асраучыларның теләкләре төрле. Без төзегән рейтингта кечкенә компаньоннар да, зур этләр дә очрый. Шулай да күпчелек халык кечкенә йорт хайванына өстенлек бирә. Эт токымын сайлаганда, хуҗа кеше аның белән нәрсә эшләргә планлаштыруын алдан уйласын иде. Мәсәлән, әгәр ул көннәр буе эштә икән, артык актив эт алудан мәгънә юк, – дип киңәш иткән оешманың матбугат үзәге.

Россиялеләр немец шпицы, чихуахуа, вельш-корги, немец овчаркасы, йоркшир терьеры, лабрадор-ретривер, Урта Азия овчаркасы, джек-рассел терьер, француз бульдогы һәм пудельга өстенлек бирә икән.

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тәкъдим иткән мәгълүматлар буенча, республикада этләрне вакытлыча яшәтер өчен 16 приют бар. Аларның күпчелеге Казан, Чаллы, Әлмәт, Алабуга, Түбән Кама шәһәрләрендә урнашкан. Шулай ук Лаеш, Биектау, Питрәч, Азнакай, Балык Бистәсе районнарында да хуҗасыз этләрне аулау белән шөгыльләнүче оешмалар эшли.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 декабрендә кабул ителде

1 статья

«Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 10 (II өлеш); 2014, № 11 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның уналтынчы абзацында «Сиктерме-Хузангай» сүзен «Сиктерме» сүзенә алмаштырырга;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:



«Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче авыл җирлекләре

карта-схемадагы №	Муниципаль берәмлек
1	Аппак авыл җирлеге
2	Базарлы Матак авыл җирлеге
3	Борискино авыл җирлеге
4	Югары Колчура авыл җирлеге
5	Каргалы авыл җирлеге
6	Кошки авыл җирлеге
7	Түбән Әлки авыл җирлеге
8	Түбән Кәчи авыл җирлеге
9	Яңа Үргәагар авыл җирлеге
10	Салман авыл җирлеге
11	Иске Алпар авыл җирлеге
12	Иске Камка авыл җирлеге
13	Иске Матак авыл җирлеге
14	Иске Салман авыл җирлеге
15	Иске Карата авыл җирлеге
16	Иске Чаллы авыл җирлеге
17	Ташбилге авыл җирлеге
18	Чуаш Кичүе авыл җирлеге
19	Чуаш Борнае авыл җирлеге
20	Чиябаш авыл җирлеге
21	Юхмачы авыл җирлеге

»;

3) 17 нче кушымтаның сигезенче абзацында «Сиктерме-Хузангай» сүзен «Сиктерме» сүзенә алмаштырырга;

4) 21 нче кушымтаның дүртенче абзацында «Сиктерме-Хузангай» сүзен «Сиктерме» сүзенә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 20 декабрь. № 90-ТРЗ

«Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 декабрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 1 – 2, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле 1^1 статья өстәргә:

«1^1 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.»;

2) 4 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге күрсәтелгән органнарның тиешле структур бүлекчәләре яисә вәкаләтле вазыйфаи затлары һәм дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар (алга таба – ведомство буйсынуындагы оешмалар) тарафыннан тәэмин ителә.»;

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә урнаштырыла торган мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру**

1. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланалар, анда, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә булдырылган, мәгълүматтан файдаланучы тарафыннан гариза юллану һәм соралган мәгълүмат алыну мөмкинлеге булган электрон почта адресларын күрсәтеп, рәсми сайтлар булдыралар. Ведомство буйсынуындагы оешмалар үз карамагында мондый оешмалар булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары карары буенча, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми сайтлар булдыралар. Җирле үзидарә органының һәм аның буйсынуындагы оешманың рәсми сайтлар булдыру мөмкинлеге булмаган очракта, аларның эшчәнлеге турында мәгълүмат Татарстан Республикасы рәсми сайтында (порталында) урнаштырылырга мөмкин. Муниципаль районга керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар эшчәнлеге турында мәгълүмат шул муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин. Федераль законнар нигезендә дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм (яисә) ведомство буйсынуындагы оешмаларның берничә рәсми сайтлары урнаштырыла торган бердәм портал булдыру каралырга мөмкин.

2. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми битләр булдыралар. Ведомство буйсынуындагы оешмалар, аларның эшчәнлеге өлкәсе үзенчәлекләрен исәпкә алып, үз карамагында мондый оешмалар булган дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары белән килештереп, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми битләр булдырмаска мөмкин. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми битләр турында мәгълүмат әлеге битләрнең күрсәткечләре белән тиешле дәүләт органының, җирле үзидарә органының яисә ведомство буйсынуындагы оешманың рәсми сайтында урнаштырыла.

3. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үзләренең рәсми битләрендә мәгълүмат урнаштыруны гамәлгә ашыралар, рәсми битләрдә урнаштырыла торган мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген алалар һәм мәгълүматтан файдаланучылар белән хезмәттәшлекне, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда каралган электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм дәүләт функцияләрен һәм муниципаль функцияләрне башкару өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурадан файдаланып, рәсми битләрдә гамәлгә ашыралар.

4. Рәсми сайтлар һәм рәсми битләр «Дәүләт хезмәтләре (функцияләре) һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы белән Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган тәртиптә һәм таләпләр нигезендә хезмәттәшлек итәләр.

5. Дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм ведомство буйсынуындагы оешмаларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

6. Дәүләт органнарының һәм аларның буйсынуындагы оешмаларның, шулай ук җирле үзидарә органнарының һәм аларның буйсынуындагы оешмаларның рәсми сайтларыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программага караган һәм лингвистик чараларына таләпләр күрсәтелгән органнар тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә билгеләнә.

7. Дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм ведомство буйсынуындагы оешмаларның рәсми сайтларыннан күрү буенча инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

4) 6 статьяда:

а) исемендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә» сүзләрен «Рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 өлештә «тарафыннан» сүзеннән соң «билгеләнә торган тәртиптә» сүзләрен өстәргә;

г) түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. Ведомство буйсынуындагы оешмаларның эшчәнлеге турында аларның рәсми сайтларында урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеге үз карамагында мондый оешмалар булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 20 декабрь. № 91-ТРЗ

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 31 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 декабрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 20 статьяның 2 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) дәүләт органының административ регламенты (башка норматив хокукый акты) нигезендә гражданнарның һәм оешмаларның соратып алуы буенча күрсәтелә торган дәүләт хезмәт күрсәтүләре (эшчәнлек төрләре) исемлеге;»;

2) 31 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 6^1 пункт өстәргә:

«6^1) дәүләт хезмәткәренең мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылуына яисә аның тарафыннан хәрби хезмәт узу турында контракт йә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү хакында контракт төзелүгә бәйле рәвештә Федераль законның 53^1 статьясында каралган гарантияләр;».

2 статья

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2023 елның 3 февраленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 20 декабрь. № 92-ТРЗ

«Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 декабрендә кабул ителде

1 статья

«Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяның 2 өлешендә:

а) 2 пунктка «(шул исәптән «Посейдон» коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып)» сүзләрен өстәргә;

б) 4 пунктка «(шул исәптән «Посейдон» коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып)» сүзләрен өстәргә;

2) 8 статьяның 3 өлешенә «(шул исәптән «Посейдон» коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып)» сүзләрен өстәргә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 20 декабрь. № 93-ТРЗ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Эшендә ирешкән уңышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Татэнерго» акционер җәмгыятенең «Чаллы җылылык челтәрләре» филиалы директоры **Зәйнуллин** Айрат Зиннәтулла улы, «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең «Буа электр челтәрләре» филиалы ярдәмче станцияләр хезмәтенең Буа төркеме электр бүлгеч җайланмалар җиһазларын төзекләндерү буенча электрослесаре **Сәгъдуллин** Илсур Салих улы, «ТАТЭЛЕКТРОМОНТАЖ» акционер җәмгыятенең Икенче Казан монтаж идарәсе яктырткычлар һәм яктырту челтәрләре буенча электромонтажчысы **Фәләхов** Илгиз Галимҗан улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Бәйрәмов» бәйрәм театры» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте вокалчы артисты (солисты) **Җиһангәрәева** Ләйсән Радик кызына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе исәпләү техникасы, программа тәэминаты чараларын һәм телекоммуникация җиһазларын эксплуатацияләү бүлеге башлыгы **Коваль** Людмила Владимировнага, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары **Яковлев** Альберт Валерьевичка **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«ТГК-16» акционер җәмгыятенең «Түбән Кама җылылык-электр үзәге» (ПТК-1) филиалы электр цехы башлыгы урынбасары (релесаклагыч һәм автоматика буенча) **Емельянов** Дмитрий Ивановичка, «Түбән Кама нефтехим» гавами акционер җәмгыяте II сәнәгать зонасы заводлары электр җиһазларын эксплуатацияләү һәм төзекләндерү идарәсе этилен, стирол һәм полиэфир сумалалар җитештерү заводлары электр җиһазларын эксплуатацияләү һәм төзекләндерү цехының электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтеры **Куркин** Владислав Юрьевичка, «Түбән Кама нефтехим» гавами акционер җәмгыяте I сәнәгать зонасы заводлары электр җиһазларын эксплуатацияләү һәм төзекләндерү идарәсе бутил каучук заводы электр җиһазларын эксплуатацияләү һәм төзекләндерү цехының электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтеры **Смолин** Павел Николаевичка, «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең «Түбән Кама электр челтәрләре» филиалы Минзәлә электр челтәрләре районы Хуҗамәт участогы энергетика җиһазларын төзекләндерү участогы мастеры **Фәррахов** Данил Мозаффар улына, «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең «Буа электр челтәрләре» филиалы директорының гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары **Фәткуллов** Альберт Нәриман улына, «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең «Алабуга электр челтәрләре» филиалы ярдәмче станцияләр хезмәтенең Менделеевск ярдәмче станцияләр төркеме Красный Бор участогы ярдәмче электр станцияләре төркеме башлыгы **Шадрин** Сергей Евгеньевичка, «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең «Әлмәт электр челтәрләре» филиалы Азнакай электр челтәрләре районы башлыгы **Шәрәфиев** Айдар Әдип улына, «Түбән Кама нефтехим» гавами акционер җәмгыяте электр энергиясе белән тәэмин итү идарәсенең электр техникасы җиһазларын көйләү, төзекләндерү һәм эксплуатацияләү цехы электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтеры **Шулаев** Александр Владимировичка **«Татарстан Республикасының атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Айкина** Светлана Александровна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлеге башлыгы **Бурчин** Анатолий Николаевич, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Бота авылы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары **Зайцева** Любовь Николаевна, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге башлыгы **Исламова** Раушания Әнвәр кызы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре башлыгы урынбасары **Ксенофонтов** Михаил Иванович, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Важашур авылы башкарма комитеты секретаре **Кузнецова** Анжелла Андреевна, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай авыл җирлеге башлыгы **Мәгъсүмов** Ришат Миңневакыйф улы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Пучы авыл җирлеге башлыгы **Нуретдинов** Нияз Зәйнетдин улы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге башлыгы **Попова** Татьяна Васильевна, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Колай авыл җирлеге башлыгы **Поповская** Наталья Владимировна, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары **Бариев** Илфак Шамил улы; Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге башлыгы **Бухарова** Ирина Борисовна, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгы **Гарифуллина** Фирая Харис кызы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге башлыгы **Гыйззәтуллина** Мөслимә Фәрит кызы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге башлыгы **Григорьева** Ольга Александровна, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балтач авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Зыятдинова** Эльмира Хикмәт кызы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Тайсуган авыл җирлеге башлыгы **Мостафин** Марсель Фәхертдин улы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтеры **Рахмеева** Фәния Әбүзәр кызы, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе **Хәмидуллин** Илнур Хаҗинур улы; күпьеллык намуслы хезмәте, гражданлык хәле актларын теркәү системасын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге башлыгы **Фәхертдинова** Гүзәлия Сәгадәтулла кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Халыкара мөнәсәбәтләр институтының Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбе төбәкләрне өйрәнү һәм Евразия тикшеренүләре кафедрасы доценты **Бодров** Олег Вячеславович, «Ульяновск авиация көллияте – төбәкара компетенцияләр үзәге» өлкә дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Китаева** Наталья Николаевна, Корреспондентлык челтәре Россиядә корреспондентлык челтәре хезмәтенең «Бөтенроссия дәүләт телевидение һәм радио тапшырулары компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесенең Казан шәһәрендәге корреспондентлык пункты мөдире **Назаров** Станислав Сергеевич, хезмәт ветераны **Насыйбуллин** Шәйхулла Галимулла улы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Документлар белән тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары **Хәсәншина** Лилия Рәвкать кызы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иҗтимагый Советы әгъзасы **Һидиятов** Ринат Әлифхан улы, хезмәт ветераны **Ширшова** Надежда Александровна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чистай районы буенча бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Денисов** Олег Геннадьевичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсе 1 номерлы «Автозавод» полиция бүлегенең сорау алу бүлеге башлыгы, полиция майоры **Килина** Анастасия Владимировнага, «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты» федераль дәүләт казна югары белем бирү мәгариф учреждениесенең читтән торып уку факультеты өлкән укытучысы-методисты, полиция полковнигы **Шакирова** Елена Валериевнага **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы» муниципаль казна учреждениесенең оештыру-аналитика һәм хокукый эш идарәсе башлыгы **Әдһәмова** Лилия Шәүкәт кызына, Татарстан Республикасы Чаллы шәһәр суды судьясы **Вафина** Гөлфия Васил кызына, Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Хәсәншин** Раил Раиф улына, «Татэнерго» акционер җәмгыятенең хокук идарәсе башлыгы **Савинова** Ольга Николаевнага, дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе юридик идарәсе башлыгы **Хәмидуллина** Эльвира Альберт кызына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

УКУЧЫ СҮЗЕ

Фәния Әхмәтҗанова

БУ ЯҢА ЕЛ

Бу Яңа ел… Шик-шөбһәләр югаладыр,
Яңа елда яңа өмет уянадыр,
Искеләрен еллар кая куялардыр,
Ниләр алып килер икән бу Яңа ел?

Барыбыз да өметләнеп юанадыр…
Яңа өмет тимер түгел, пыяладыр,
Ул кайвакыт төшеп китеп уаладыр,
Абынырлык таш булмасмы бу Яңа ел?

Өметләрнең кайберләрен тыялардыр…
Буш өметтән барыбыз да моңаядыр,
Хөр бәрәкәт эстәп кемгә Ил таяныр?
Тагын өмет алып килә бу Яңа ел.

Бар ул Бәхет, йөри адашып каядыр,
Зиһененә, тәүфыйгына Ил таяныр,
Үз язмышын тырыш кулларына алыр,
Өметләрне өзмә генә, и Яңа ел!

Башыбызда төрле уйлар чуаладыр,
Өметләр дә төрле төскә буяладыр,
Яше-карты бәйрәм итә, куанадыр,
Мәрхәмәтле булчы безгә, и Яңа ел!

Рәниф ШӘРИПОВ

НУРДИДӘ АПА ЧЫРШЫСЫ

Бөтен җиһан ап-ак. Ак кар өстеннән акрын гына урам буйлап атлыйм, тәрәзәләргә күз салам. Һәр йортта диярлек, бер кабынып, бер сүнеп, мавыктыргыч утлар яна, халык Яңа ел бәйрәменә әзерләнә. Тик көенечләр булмасын, һәр йорт сөенеч, бәхет тулы авазларга гына күмелсен. Кышкы бәйрәм алдыннан һәркем хатирәләр белән яши, балачагына кайта. Күңелле мәшәкать шул ул Яңа елны каршы алу…

Без кечкенә чакта декабрь ае башыннан чәй төргән кәгазьләрдән чыршы бизәү өчен уенчыклар, җәнлекләр ясый идек. Бу шөгыль күңелгә бәйрәм рухы өстәде. Җәнлек битлекләренә кадәр үзебез ясадык. Шуңа да алар безгә кадерле иде. Ә хәзер бөтенесе кибеттә бар.

Сүзем – Зәй районы Сармашбаш авылында җитмешенче еллар чоры балаларының Яңа елны бәйрәм итүләре турында. Бәйрәм алдыннан өйдә күңелле ыгы-зыгы. Әткәй ат чанасы белән чыршы алып кайта. Аны урнаштыру, үзебез ясаган уенчыклар белән бизәү барчабызга рәхәтлек өсти. Безне шул рәвешле сөендерә алуыннан әтинең канәгать булуы йөзенә чыга. Күрәсең, без – алты баланың сөенечле йөзен күрү ата-анага рәхәтлек өстәгән.

Авылда каршы як тау башында яшәүче Нурдидә апа Биктимерова да чыршы бизи. Ул читтән күченеп кайткан иде. Уенчыклары да чып-чын, ялтыр-йолтыр килеп тора. Яна торган лампочкаларына хәтле бар. Нурдидә апа, безне җыеп, ел да бәйрәм ясады. Ул көнне карда бата-чума, шабыр тиргә баткан балалар Нурдидә апа яшәгән тауга агыла иде. Ул үзе – Кыш бабай, аның яшүсмер кызы Зөбәрҗәт Кар кызы булып киенеп, тау башында безне көтеп алалар. Без башта аларны урманнан килгән чып-чын Кыш бабай белән Кар кызы дип уйлый идек. Әле мәктәпкә укырга йөрми идек бит, авылда балалар бакчасы юк, шуңа да күмәк бәйрәмдә катнашкан булмады. Нурдидә белән Зөбәрҗәт апалар балаларны чыршы тирәли әйлән-бәйлән уйнаталар, җырлаталар, бүләк өләшәләр. Без, 4–5 яшьлек авыл балалары, Чыршы бәйрәмен тагын кайда күргән булыр идек?! Балалык белән аларга рәхмәт тә әйтелмәгәндер. Нәниләргә күпме сөенеч, шатлык өләшкәннәр. Кем ничек савап эшли бит. Алар хәзер икесе дә бакыйлыкта инде. Ә без ел саен әлеге сихри балачак чыршысын искә алабыз. Безне сөендергән авылдаш апаларның рухлары шат булсын.

Рәзимә КАШАПОВА.
Зәй

УКЫТЫП БЕТЕРГӘНЕН КӨТМӘДЕЛӘР

Беренче дәресне мин Әлмән башлангыч мәктәбенең директоры булган укытучы Галия Сәйфуллинадан алдым. Миңа 6 яшь, мәктәпкә кермәсәм дә, укыйсы килә. Үземнән 5 яшькә олырак күрше Хәлимә апага ияреп укырга киттем. Мәктәп – авыл читендә, ишегалдында – укучылар утырткан алмагачлар. Традиция буенча 1 нче сыйныфка керүче һәр бала мәктәп бакчасына агач утырта иде. «Мин әтием белән слива утыртачакмын!» – дип күптән ниятләп куйган идем.

Укытучы Галия апа мине беренче партага утыртты. Аның ямь-яшел йон күлмәге бүген дә күз алдымда, укытучыларга хас җитди тавышы – колагымда. 1950 нче елларда Чуашстанның Батыр районында хөкемдар булып эшләгән кеше бит ул! Авылыбызда аны бик хөрмәт итәләр иде.

1968 елның 1 сентябрендә безне, мәктәпкә кергән балаларны, яшь кенә егет – Минҗан абый Дәүләтбаев каршы алды. Ул Арча педагогия училищесын тәмамлап, безгә эшкә җибәрелгән иде. Укытучы абыебыз безне хәреф танырга, санарга, кулыбыздан тотып язарга өйрәтте. Тәнәфесләрдә ул, тәрәзә янына килеп, Бәчек тавына карап, моңлы итеп җырлый иде:

Әй, Кыйзаш, Кыйзаш…

Нәкъ «к» хәрефен өйрәнгәч, укытучы абыебызны армия сафларына алдылар. «Нишләп безне укытып бетергәнне көтмәгәннәр инде?» – дип уйлаганым истә. Укытучыбызны озатырга әти-әниләребез дә станция юлына кадәр барды.

Гармунчыбыз бию көен уйнады, ә абыебыз һәрберебез белән биеде. «Әлифба» тәмамланмаган иде бит әле. Безне Кармыш урта мәктәбендә пионервожатый булып эшләүче, Минзәлә педагогия училищесын тәмамлап, юллама белән килгән яшь кыз Галия Рамазанова укыта башлады. Укытучыбызны бик яраттык, тырышып укыдык. Аны озатырга авыл читенә кадәр бара идек, Кармыштан, өч чакрым арадан килеп йөрде бит. Бергәләп стена газетасы чыгардык, значоклардан коллекция тупладык, музей почмагы булдырдык. Галия апа мандолинада уйный иде. Без «Уракчы кыз», «Чапаев абый», «Ямьле безнең Минзәләбез» җырларын мандолинага кушылып җырлый идек. 8 Март – Халыкара хатын-кызлар көненә әби-әниләребезгә табын әзерләп концерт куйдык. Ак бүзгә мулине белән чәчәк чигеп, кульяулык бүләк иттек. Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар һәйкәле янында пионерга кергәндә тантаналы вәгъдә биреп, муенга кызыл галстук тагу мәңгегә истә калырлык хатирә булды.

Беренче сыйныфта октябрятка, аннан пионерга керүебез – мәңгелек якты истәлек. Аннан соң безгә Абдулла Мөхәммәтҗан улы Хөснетдинов белем бирде. Хәрбиләрчә ыспай гәүдәле укытучыбыз бәйрәм тантаналарында Бөек Ватан сугышында бүләкләнгән орден-медальләрен тагып килә иде. Сугышта күргән вакыйгалар турында сөйли иде. Без аның белән бик горурлана идек.

«Солдатлар», «Священная война», «Если завтра война» җырларын укытучыбыз онытылмаслык итеп өйрәтте. 1 Май, 9 Май, 7 ноябрь бәйрәмнәрендә Әлмән башлангыч мәктәбенең барлык укучыларын Абдулла абый Хөснетдинов тантаналы демонстрациядә йөртә иде. Быргы, барабан, байрак күтәреп йөрергә алдынгы укучылар гына лаек!

Укытучы абыебыз белән урман-кырларга сәяхәт иттек. Җир, кояш, башка планеталар турында сөйләде ул. Без, 3 нче сыйныф укучылары, миллион, триллион саннарының бик күп икәнен белә идек инде. Агач, үләннәрне өйрәндек, учакта бәрәңге пешердек. Җиде төрле үлән җыеп, кыйбладан ага торган Чашлама суын савытларыбызга тутырып, әти-әниләргә алып кайта торган идек. Ветеран укытучыбыз туган илебезне яратырга, әти-әнине, өлкәннәрне хөрмәтләргә, табигатьне сакларга өйрәтте, олы тормыш юлына әзерләде. Без мәрхүм укытучыларыбыз рухына дога кылабыз, исәннәренә рәхмәт әйтәбез.

Равилә МӨБАРӘКШИНА.
Чуашстан, Әлмән

ЭЧТӘГЕ КОРТТАН КОТЫЛУ КИРӘК

Бәрәңге корты хакында онытып өлгермәгән идегезме әле? Әтнә районы мәдәният хезмәткәрләре кабат искә төшерделәр бу мәшәкатьләрне.

Районыбызның Яңа Әтнә мәдәният йортында Арча районында туган, башкала театрларында актер булып эшләп, Татарстанның халык артисты дәрәҗәсенә ирешкән, авыл тормышын белеп, аны төрле яклап яктырткан драматург, режиссер Фәнәвил Галиевнең (рухы шат булсын) «Корт» пьесасы буенча куелган «Авылым» спектакленең премьерасын карадык. Карадык та көлдек. Комедия жанры гел шулай, башта көлдертә, аннан уйлата, хәтта елата. Чөнки артистлар үзебезгә, милләткә хас җитешсезлекләрне күрсәтә.

…Сәхнәдә – «Медосмотр» дип язылган машина. Урындыкларга тезелеп утырган халык. Чират күп. Ул да түгел, берсе, торт күтәреп килеп, шәфкать туташына суза. Икенчесе акча төртә. Хәллерәкләр болар. Гади халык шыпырт кына чиратның артына барып баса. Таныш хәлләрме? Таныш. Менә шушы чиратта торганда дөнья хәле, борчыган мәсьәләләр кузгала да инде. Җәй аенда бәрәңге кортыннан да кулае юк. Ә аны бетерә торган түгел. Ярар иде бар бакча бертөрле булып, бар да әллә ничә кат агуласа. Юк шул, 40 яшьлек Хәйдәрнең (Фәрит Борһанов) бакчасында бер генә корт та юк. Җитмәсә, бәрәңгесе дә башкаларныкы ише күкәй кадәрле генә түгел, баш хәтле. Автор бөтен фәлсәфәне дә, вакыйганы да менә шушы бәрәңге корты тирәсенә җыйган да кемнең кемлеген, ни рәвешле яшәгәнен ачып салган. Көлсәң көл, уйласаң уйла. Без, тамашачылар, спектакль барышы буенча көлдек, хупладык, алкышладык. Уйларга әллә ни вакыт та калмады, вакыйгалар үз эченә бөтереп алды. Сәхнәдәге авылны да, безне дә бәрәңге корты борчыды. Ничек кортсыз бәрәңге үстереп була? Хәйдәргә дә бик еш бирделәр бу сорауны. Башкаларга әйтмәс дип, серен белү өчен, сөйгәне Сәлимәне (Гөлия Шәйхиева) Хәйдәр янына җибәрделәр.

– Әйт инде, нинди агу сиптерәсең син аңа?

– Сиптермим, җыям мин ул кортларны! – дип серне чиште Хәйдәр. Тик андый гадилеккә кем ышансын? Сәлимә дә Хәйдәрне галстугыннан тотып кына селкеде.

Соңрак Хәйдәргә бу сорауны аңа гашыйк 23 яшьлек кыз Рамилә (Альбина Хәкимова) дә бирде, «…серен ачмасаң, әниләр сиңа кияүгә бирмиләр», – дип ямансулады.

– Җыям мин аларны. Бәрәңге сабагы бит ул селкетеп торганны ярата, һәр иртә саен бөтен төпләрне селкетеп чыгам, 15 минут җитә, – дип әйтеп карады Хәйдәр. Тик ышандыра алмады.

Авыл советы рәисе Гаптерине (Рәсим Галимҗанов) дә борчый корт мәсьәләсе. Хәйдәр аңа да аңлатып карый. Юк инде, нинди ышану, безнең халык дару ашап, агу ашап күнеккән, әллә нинди ачышлар кирәк безгә. Спектакльдә дә шулай. Автор менә шушы кимчелекләрне шулкадәр оста чагылдырган.

Спектакльдәге бер эпизодта, ат типкәч, без дә Хәйдәрне үлгән дип уйладык. Сер китеп барды, дип борчылды аның авылдашлары да. Тик кеше үлү борчымады да күк, кортны бетерү серен белми калу аянычрак булды. Бөтен кешенең серен белеп, аны дәфтәргә язып барган, барысын килештереп йөргән, үзенең фамилиясен дә оныткан йөз яшьлек Саҗи әбидән (Ләйсән Дәминова) барысы да:

– Нәрсә дип әйтеп калдырды? – дип сорадылар.

– Кортларыннан котылсыннар, – диде.

– Тагын?

– Эчләрендә корт булмасын, диде, эчегездәге корт бакчагызга да чыга, – дип әйтеп, карчык җитди генә китеп барды.

Әсәрдәге бөтен фәлсәфә дә шушы соңгы җөмләләргә сыеп бетте. Артистларның уены менә шуны аңларга ярдәм итте.

Спектакльдә һәр артист үз роленә туры китереп сайланган. Әтнә татар дәүләт драма театры артисты, режиссер Дамир Сидеевнең иң зур уңышы да шунда. Декорация дә бик уйланып, зур осталык белән ясалган. Вакыйгалар алышынганда бернинди ыгы-зыгы юк. Артистлар күп, дистәдән артык, сәхнә кечерәк булгач, азрак куркыткан да иде. Ә алар бәрелмәделәр дә, сугылмадылар да, тотлыкмадылар да, каушамадылар да.

Фәнәвил Галиевнең җәмәгате, спектакльне карарга кайткан Әминә ханымның әлеге спектакльне матур мизгел дип, шигъри сөйләм белән бәяләп, «Менә шундый фанат кешеләребез булганда гына, безнең милләтебез яшәр, телебез яшәр…» – дип рәхмәт әйтүен дә артистларның чыгышына зур бәя дип саныйм.

Мәдәният хезмәткәрләренең (күбесе – авыл мәдәният йорты җитәкчеләре) тиз арада өйрәнүләрен, беренче тапкыр җыйналып, спектакль сәхнәләштерүләрен (ничек өлгерәләрдер!) истә тотсак, «Авылым» спектакле – матур башлангыч. Уйный-уйный остарачакларына бернинди шик юк. Дәвамлы булсын. Әтнәлеләр шундый теләктә калды.

Сүрия МИНГАТИНА.
Әтнә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз тугызынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 375-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
3. Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзаларын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләрен сайлау турында.
4. Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары вәкаләтләрен туктату турында.
5. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 369-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 370-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 372-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләр раслау хакында» 373-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Удмуртия Республикасы арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү (тасвирлау) турында 2022 елның 19 декабрендәге 61 номерлы килешүне раслау хакында.
10. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 368-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 367-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 371-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында.
13. «Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 360-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 366-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 363-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 359-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
17. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 246186-8 номерлы федераль закон проекты хакында (салым түләүчеләр – физик затларның салым органнары белән электрон рәвештә хезмәттәшлек итү тәртибен камилләштерү өлешендә).
18. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 71 статьясына үзгәреш кертү хакында» 200890-8 номерлы федераль закон проекты турында (бакалавриат һәм специалитет программалары буенча укырга кабул иткәндә, рәсми спорт ярышлары җиңүчеләренә аерым хокуклар бирү өлешендә).
19. «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 232776-8 номерлы федераль закон проекты турында (тимер юлларда урнашкан күперләрне һәм тоннельләрне эксплуатацияләү хакында).
20. Хәрби хезмәт узган, эчке эшләр органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында, җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарында хезмәт иткән затларны һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 226676-8 номерлы федераль закон проекты турында (мобилизацияләнгән гражданнарга пенсия түләүне дәвам итү турында).
21. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 13.15 статьясының 5 өлешенә үзгәрешләр кертү хакында» 253972-8 номерлы федераль закон проекты турында (массакүләм мәгълүмат чараларында утлы корал өчен ату кирәк-яракларын законсыз әзерләү инструкцияләре булган белешмәләр тараткан өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).
22. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39^{5} һәм 39^{10} статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.
23. 2022 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.
24. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре. 2022 елның 23 декабре
№ 1750-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп чикләнмәгән вакытка түбәндәгене сайларга:

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Яңа Савин суд районы буенча:

3 нче суд участогына – Зәйнетдинов Раян Мансурҗан улын.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре. 2022 елның 23 декабре
№ 1754-VI ДС

Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзаларын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләрен сайлау турында

«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре итеп түбәндәгеләрне сайларга:

Вальщиков Әмир Габдулла улын;
Сергеев Тимур Григорьевичны.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре. 2022 елның 23 декабре
№ 1755-VI ДС

Свидетельство об окончании автошколы ООО «Драйв», выданный в марте 2021 г. на имя Моисеичева Дамира Ирековича, в связи с утерей считать недействительным.

БИЛГЕСЕЗ БАТЫРЛЫК

Ватан хакына

Илдар турында берәр яңа мәгълүмат булмас микән, дип көтә-көтә, айлар узып китте. Махсус хәрби операциядә һәлак булган Илдар Сәйфуллинны быел июль аенда җирләгәннәр, Ютазы халкы аны олы хөрмәт белән соңгы юлга озаткан. Ютазыга баруымның максаты солдатның тормышы, язмышы турында күбрәк мәгълүмат туплау иде.

Әмма капитан Сәйфуллин гомеренең соңгы мизгелләре, кайда ничек һәлак булуы турында берни дә белә алмадым. Андый мәгълүмат гомумән юк иде. Әтисе Илдус, әнисе Резеда белән гел хәбәрләшеп тордык. Әмма алар да бернинди яңалык хәбәр итмәделәр. Шул ук вакытта Ватан солдаты – Илдар турында берни язмыйча кала да алмый идем.

Сүз бер Илдар турында гына да түгел, Бөек Ватан сугышы тәмамлануга инде 77 ел вакыт узып китте, ә Ватан солдатлары турында мәгълүматлар әледән-әле ачыклана тора. Алар – ил тарихындагы зур, гыйбрәтле бер сәхифәнең шаһитлары. Язмамның герое Илдар Сәйфуллин да – шундыйларның берсе. Аны җирләргә Ютазыга сугышчан дуслары да кайткан булган. Илдарның әти-әнисенә алар да берни әйтмәгәннәр. Дөрес, Резеда аларның нидер пышылдашуларын ишеткән. «Командир безне үлемнән коткарды, ә без аны саклап кала алмадык…» – дигән сүзләре колагына кергән. Әмма Резеданың якынлашканын күргәч, егетләр туктап калган һәм башка берни дә дәшмәгәннәр.

Резеда белән шактый сөйләшеп утырдык без. «Кечкенәдән мөстәкыйль булып үсте, гаделсезлекне җене сөймәде, кыерсытылганнарны якларга һәрвакыт әзер иде», – дип сөйләде ул.

Әле Чиләбедә хәрби академиядә укыганда ук, курсантларны кыйный дип, Илдарны академиядән куарга да теләгәннәр. Ә бу «кыйнау» дигәннәре көчсезләрне яклау булган. Ягъни үзләрен «дед»ка санап, яшьрәк курсантларны кыерсытучыларны бөтереп алып егып сала да өсләренә менеп утырып, гафу үтендерә торган булган Илдар. Бу, әлбәттә инде, «дед»ларга ошамаган һәм алар «сугыш чукмары» өстеннән шикаятьләр язгалаганнар.

Резеда моны моңсу гына елмаеп сөйли. Улының «кыланмыш»лары турында аңа да хәбәр килгән булган икән.

Украинада барган махсус хәрби операциядә һәлак булгач, командование Илдарның әти-әнисенә хат җибәрә, анда «улыгыз чын офицер иде» дигән юллар була. Бу сүзләр ата-ананы тынычландыру, алар күңелендә уллары белән горурлану хисләре тудыру өчен генә язылмагандыр дип уйлыйм. Чөнки Илдарның бөтен тормыш юлы батырлыкка баруны хәтерләтә.

Беренче елны Чиләбедәге хәрби уку йортына керә алмый егет. Әнисе: «Улым, бәлки, башка җиргә кереп карарсың, башка һөнәр сайларсың», – ди. Илдар исә: «Әни, укырга йә шунда гына керәм, йә беркайда да укымыйм», – дип кырт кисә. Һәм бер ел узгач, яңадан Чиләбегә бара,

Гаилә архивыннан

имтиханнарны уңышлы тапшырып, хәрби академия курсантына әйләнә. Имтихан алучылар аны хәтерләп калган булганнар икән. «Вот, упрямый татарин!» – дип тел шартлатканнар ди. Илдарны, әлбәттә инде, офицер киеме киеп йөрү генә кызыктырмаган. Ул малай чактан ук Ватанны сакларга әзерләнгән дип уйлыйм. Чиләбедә югары хәрби училище, аннан соң Томскида Россия Кораллы Көчләренең гомумгаскәр академиясе филиалын тәмамлаган егет махсус операцияләр буенча белгеч була. Шуңа күрә Илдарны мотоукчылар батальонының разведка взводы командиры итеп куялар. Разведканы гаскәрләрнең «колагы һәм күзе» белән чагыштыруларын искә төшерсәк, 24 яшьлек егетнең үзенә нинди зур җаваплылык алуын чамаларга мөмкин.

2019 елда Илдар Сәйфуллинны Көнбатыш хәрби округка җибәрәләр, шунда рота командиры итеп билгеләләр. Аның хәрби тормыш юлы турында саран гына мәгълүматлар бу. Ничек хезмәт итүе турында Илдар үзе дә беркемгә сөйләми. Әнисе кайчан гына сораса да: «Бөтенесе дә әйбәт», – дип кенә җавап бирә торган була.

Күптән түгел абыйсы Илнур миңа бер видео җибәргән иде. Илдар сугышчан дуслары белән – БТРда. Барысы да туганнарына сәламнәр юллыйлар, бездә бөтенесе дә әйбәт, диләр. Шунда Илдарның: «Фашистлар дөмектереләчәк!» – дип кычкыруы аермачык ишетелеп кала. Бу – бәлки, чираттагы операция алдыннан төшерелгән соңгы язмадыр. Аны 4 яшьлек кызы Альяна да карагандыр. Юкса әтисе белән горурланып, сабыйларча шатланып, бүген дә: «Минем әти – супергерой!» – дип сөйләп йөрмәс иде. Илдарның хатыны Идалия дә ире хезмәт иткән хәрби частьның госпиталендә эшләгән һәм бүген дә шунда ди.

Бүген без патриотизм хисләре тәрбияләү турында күп сөйлибез. Кайчак бу хис безнең геннарга салынгандыр кебек тоелып китә. Минем ил тарихының шактый ук дәрәҗәдә сугышлардан торуы турында язганым бар. Бүген янә ил тарихына күз салдым. Әйе, сугыш-чуалышлар һәр буынга туры килеп барган. Әмма халкыбыз, нигездә, ил иминлеген саклау өчен көрәшкә күтәрелгән. Бүген дөньясына әллә ни булды. Заманында дөньяны фашизмнан азат итүдә безгә теләктәшлек күрсәткән илләрнең кайберләре, тәртәләрен кире борып, әлеге афәтне яклый башладылар, аларда совет солдатларының батырлык символы булган һәйкәлләр юкка чыгарыла бара. Әмма хәтерне җимереп булмас. Фашизм – кайсы заманда да фашизм инде ул. Ә афәт алдында берләшү шулай ук безнең геннарга салынган кебек. Яшь офицер Илдар Сәйфуллин да БТРга утыргач: «Фашистлар дөмектереләчәк!» – дип юкка кычкырмагандыр дип уйлыйм.

Язмама нокта куяр алдыннан яңа хәбәр алдым. Ютазыга Илдар Сәйфуллин кул астында хезмәт иткән Артем исемле егет кайткан. Илдарның әнисе Резеда моны шаккаткыч вакыйга итеп сөйләде. «Ничә йөз чакрымнар узып, безне эзләп тапкан бит!» – диде. Артемны Ютазыга берәү дә юлламаган. Солдатлары өчен аталарча кайгырткан, җанын кисеп бирергә әзер торган асыл егет үстергән өчен Илдарның әти-әнисенә рәхмәт әйтергә дип, үзе махсус кайткан Артем.

Язмама «Билгесез батырлык» дигән исем кушуым, бер уйлаганда, шартлы гына. Россия Президенты Владимир Путин: «Махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәрберсе – Герой», – дигән иде. Без исә, әлеге геройларны барларга, алар турында язып, сөйләп, фильмнар төшереп, һәйкәлләр торгызып, аларның данлы исемнәрен тарихта, кеше хәтерендә калдырырга тиешбез. Халык үз батырларын белсен. Иң яхшы тәрбия – үрнәк, гыйбрәт бит ул.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Эшләгәнне күрсеннәр

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ УЗЫП БАРУЧЫ ЕЛГА ЙОМГАК ЯСАДЫ

Нәтиҗә

Сабантуй һәм чәкчәк белән генә чикләнмиләр. Кирәк җиргә татар матбугатын, дәреслекләрен дә җибәрәләр, читтәге милләттәшләрне дә барлыйлар, сөйләшәләр, очрашалар. Быел 30 елын тутырган Бөтендөнья татар конгрессы, журналистларны җыеп, узып баручы елга йомгак ясап, бу елда башкарган һәм киләсе елга ниятләгән эшләре турында сөйләде.

Татарстан Премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев сүзләре белән әйтсәк, бу ел вакыйгаларга бик бай булды. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын зурлап уздыру, төбәкләрдәге иҗтимагый оешмалар активы белән округ утырышлары, эшмәкәрләр җыены, төрле дәрәҗәдәге һәм төрле җирләрдә узган Сабан туйлары, журналистлар форумы, конгресс съезды дисеңме. Болар – әле телгә кереп калган чаралар гына. Хәер, милләт өчен эшлим дигән, башкарган эшләрнең вагы-эресе юктыр да ул. Иң мөһиме – аларны башкарганда бердәм һәм бергә буласы. Милли Шура рәисе дә шулай ди бит.

Бу елга йомгак ясау белән, киләсе 365 көн турында уйлый башларга кирәк. Милли Шура рәисе искәрткәнчә, киләсе ел татар дөньясы өчен Дастаннар елы буларак игълан ителәчәк. Моңа өстәп, Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы икәнен дә онытмаска. 2023 елда Сабан туен да башка дәрәҗәдә һәм миллилекне кайтарып үткәрәсе килә. Өственә тәүге тапкыр Идел буе Сабан туен оештырырга исәпләре. Монысы 41 төбәкне берләштергән милли бәйрәм булырга тиеш.

Журналистлар җыелгач, сорауларсыз да булмый, билгеле. Әйтик, барыбызга да мәгълүм геосәяси вазгыятькә бәйле рәвештә, чит илләрдә яшәүче татарлар белән эшчәнлек ничек алып барылачак? Васил Шәйхразыев бу җәһәттән бернинди дә мәшәкатьләр булмас дигән фикердә.

Төбәкләргә дәреслекләр җибәрү мәсьәләсе дә күтәрелде. Васил Шәйхразыев әйтүенчә, Росия төбәкләренә татар теле дәреслекләрен гариза нигезендә җибәрәләр.

– Дәреслекләрне ел саен таратабыз. Машиналарга төяп җибәреп торабыз, – диде ул. – Әгәр дә кайдадыр нидер җитми икән, бу хакта безгә җиткерергә кирәк. Дәреслекне төбәккә илтү өчен Мәгариф министрлыгыннан лицензия алырга тиеш без. Хәзерге көндә 44 дәреслек нигезендә сертификация үтәбез. Кулланмалар да бар. Кемнәр гариза бирә – без шуларга төяп җибәрәбез. Моның өчен бюджеттан ел саен акча бүлеп бирелә.

Тагын бер авырткан урын – кадрлар мәсьәләсе. Татар теле укытучысы, татар телендә язучы журналист дисеңме – барысы да кирәк. Каләм тибрәтүчеләр чит төбәкләргә бигрәк тә кирәк. Бу җәһәттән дә уйлап бетерәсе бар. Бәлки, квота нигезендә укытып булыр дигән теләк тә яңгырады.

КЫЗНЫҢ КӘТТӘСЕН ЭЛӘКТЕРГӘН!

Үрнәк гаилә

Озак еллар Арча педучилищесының директоры булып эшләгән, исеме легендага әверелгән Илдус абый Сәгъдиев гаилә тормышында да үрнәк булды. Быел хәләл җефете, безнең химия укытучысы Флюра апа белән тормыш итә башлауларына 60 ел тулды.

Без, республиканың гына түгел, Россиянең төрле почмакларында яшәүче меңләгән укучылары, бу уңайдан гөр килеп шатланыштык, мөгаллимнәребезне чын күңелдән котладык, аннан, хатирәләргә бирелеп, тынып калдык бугай. Үзем дә шул халәттә. Арча урамнарын иңләп йөрүләребез әле кайчан гына иде бит. Хәер, кайчан гына түгел, 50 ел үтеп киткән икән инде. Ул вакытта без, 14–15 яшьлек кызлар-малайлар, зур дөньяда яши башладык: ят җирләр, күрмәгән-белмәгән кешеләр… Әмма бу беренче мәлгә генә шулай булды. Укытучыларыбыз безнең өчен бик тиз якын кешеләргә әверелде.

Сүзсез калдык

Флюра Гумәровна беренче дәрескә килеп кергәч, без, аңа карап, сүзсез калдык. Йөзләре янып, күзләре балкып торган гүзәл кеше иде ул. Алай гынамы соң? Ягымлы, ярдәмчел, игътибарлы, сүзсез дә аңлый кебек. Бөтен яхшы сыйфатларны үзенә җыйган, диярсең. Чәч йөртүләре, киемсалымы дисеңме тагын! Кыскасы, безнең кебек әллә ни күрмәгән авыл кызлары өчен менә дигән эталон иде Флюра апабыз. Шул хакта серләшеп кенә бетергән идек, барыбызны да тагын бер кат сүзсез калдырган хәбәр ишеттек: бездә соклану уяткан укытучыбыз математика укытучысы Илдус Габдрахмановичның хәләл җефете булып чыкты. Ахырда: «Буе бәләкәйрәк булса да, кызның кәттәсен эләктергән», – диюдән башканы әйтә алмадык.

Бу икәүнең барыбызга да үрнәк булырлык гаилә икәнлегенә без тора-бара төшендек. Беренче мәлдә артык таләпчән булып күренгән Илдус абыйга да бик тиз ияләштек. Ике елдан аны завуч итеп куйдылар да дәресләрен кыскарттылар. Математика фәненнән безнең төркемне аның укучысы укыта башлады. Бу хәл белән килешә алмадык кына бит. Контроль эшләрне сыйныфыбыз белән начар билгеләргә эшли башладык. Кыскасы, математиканы аңламас дәрәҗәгә җиттек. Кәеф бөтенләй төште. Бу халәтне Илдус абый үзе генә төзәтә алды. Ул безгә яңа укытучыны кабул итәргә, тырпаерга түгел, киресенчә, ярдәм итәргә кирәклеген аңлатты. Без – булачак укытучылар бит. Әгәр үзебез дә шундый хәлдә калсак? Менә шуны төшендерде остазыбыз. Ниһаять, эшләр җайланды. Әмма Илдус абый укуны тәмамлаганчы безне күз уңыннан ычкындырмады.

Өченче курста укыганда Арча мәктәпләрендә башлангыч сыйныф укучыларына дәресләр бирә башладык. 1 нче мәктәптә, кызлары Лилия белән уллары Роберт укыган сыйныфларда дәрес бирү безгә аеруча җаваплылык өстәде. Барып чыкмаса, әти-әниләренә кайтып әйтсәләр, оятыңнан нишләрсең, дигән курку булган, күрәсең.

Хәлләр ничек?

Сабакташлар белән телефоннан еш аралашабыз. Сөйләшә башлауга, беренче булып: «Илдус абый белән Флюра апаның хәлләре ничек?» – дигән сорау бирәләр. Бәхеткә, һөнәремә күрә миңа остазларым белән гел аралашып яшәргә туры килде. Арча якларына командировкага килгән саен, кагылып китәргә тырышам. Мин килгән җиргә Илдус абый үзе дә йөгереп килеп җитәр иде. Рәхмәт яусын, ияртеп, аңлатып, геройларым белән таныштырып йөргән чаклары да күп булды. Мин – аның өчен һаман укучы бала әле. Аннан килеп, Арчада нинди генә чара узса да, Илдус абыйдан башка булмагандыр ул. Педучилищедан киткәч, озак еллар районда ветераннар оешмасын да җитәкләде. «Ватаным Татарстан» газетасы оештырган Китап һәм театр бәйрәмендә дә «Районда газетаны иң озак укыган кеше» номинациясендә җиңеп чыкты. 1951 елдан бирле, кайда гына яшәсә дә, аның өенә Татарстанның баш газетасы (үзе шулай ди) килеп тора. Әйтүенчә, бер җөмләсен дә укымый калдырмый икән. Ул гына да түгел, һәр язма турында диярлек фикерләрен әйтеп шалтырата да әле. Аның һәр сүзе үтемле, хәтта тәнкыйть сүзен дә бик урынлы җиткерә белә. Кайчагында мин аны: «Флюра апаны гел калдырып йөрисез», – дип, шаярту катыш шелтәләп тә алам. «Бер минут та вакыты юк. Мәчеткә йөри. Биш вакыт намазын да калдырмый», – ди Илдус абый.

Язмый калып булмый

Парлап йөргән урыннары да күп, әлбәттә. Әгерҗе кызы Флюра белән Биектау районы Урал авылы егетен үз иткән Арчада күпме дуслары, укучылары бар аларның. Бу җәһәттән гел: «Сез – бик бәхетле кешеләр. Капка төбенә чыгу белән, ерактан күреп, барысы да исәнләшә, хәлләрегезне сораша башлый», – дим. Чөнки мондый күренешкә үземнең дә әллә ничә тапкыр тап булганым бар. Урамга чыксаң, Илдус абый белән тыныч кына сөйләшеп барам димә инде. Ә педагогия көллиятендә Сәгъдиевләр – көтеп алынган кунаклар. Бергә яши башлауларына 60 ел тулган юбилейларына да көтмәгәндә кунакка чакырганнар аларны. Үзләрен генә түгел, бергә эшләгән укытучыларны да җыйганнар. «Аларның күбесе – минем укучыларым яки мин эшкә алган кешеләр инде», – ди Илдус абый. Икесенең дә бик күңеле булган. Бу хакта көллиятнең бүгенге директоры Гөлнара Гарипова белән дә гәпләшеп алдык.

– Илдус абый белән Флюра апа – безнең киңәшчеләребез дә, ярдәмчеләребез дә, – ди ул. – Нинди генә сорау килеп туса да, башлап аларга шалтыратам. Тәҗрибәгә бай булгач, әйтер сүзләре дә күп. Беркайчан да авыр хәлдә калдырмыйлар. Студентлар өчен дә үрнәк алар. Нинди мөгаллимнәребез барлыгын күреп, белеп торсыннар дибез.

Юбилей дигәннән, Илдус абый әйтүенчә, алар бу көнгә әллә ни игътибар да итмәгәннәр. Ә менә балалары, укучылары чын бәйрәм ясаган. Көн-төн телефон шалтыраудан туктамаган. «Безнең өчен иң кадерлесе шул булды. Инде педучилищены әллә кайчан тәмамлаган укучыларыбыз котлады. Каян белеп бетергәннәр? – дип гаҗәпләнгән була үзе. «И Илдус абый, сезне ничек онытып була инде?» – дигән булам. Нинди генә әйбәт кеше булса да, барлык даталарны күз уңында тотып булмый инде анысы. Бигрәк тә мәгълүмат кайнап торган бүгенге дөньяда. Әмма дөресен әйтим: ул көнне төрле елларда педучилище тәмамлаган кешеләрне берләштергән чатлар «кайнап» торды. Бу җәһәттән шунысын да әйтергә кирәк. Инде 9 нчы дистәне куып барсалар да, Сәгъдиевләр цифрлы җиһазлар белән идарә итү өлкәсендә бер дә кимен куймыйлар.

Илдус абый белән Флюра апаның өч баласы, биш оныгы Казанда яши хәзер. Кайчагында, берсе дә Арчада калмады, дип борчылып та куялар. Андый вакытларда: «Кайгырмагыз, Казан белән Арча тоташкан бит инде хәзер», – дим. Күңелләре күтәрелеп китә. Чыннан да шулай. Балалары, оныклары гел кайтып, әти-әниләренең хәлләрен белешеп торалар. Лилия белән Роберт Казан төзелеш институтында укыган булсалар, Тимур нәкъ менә әтисенең эшен дәвам иттерде. Башта педучилищены тәмамлады да педагогия институтының физмат факультетында белем алды. Хәзер Казанның 57 нче мәктәбен җитәкли. Бу юлы да, һәрвакыттагыча, әти-әниләренә чын бәйрәм ясаган алар.

– Галәмәт кыландылар инде, – ди Илдус абый, көенгән булып сөенә-сөенә. – Казанга алып китеп, өч көн буена мәҗлес оештырдылар. Истәлекле урыннарда йөрттеләр. Без Флюра апаң белән Ленин урамындагы ЗАГСта язылышкан идек. Шунда бардык. Хәзер анда банк урнашкан икән. Студент чагында «монастырь»да урнашкан тулай торакта яшәдек. Аны да күрсәттеләр. Беренче тапкыр очрашып танышуыбыз да шунда булган иде. Бик матур итеп видеоларга төшерделәр. Вакыт-вакыт уңайсыз да булып китте. Алай ук кирәкмәс иде инде. Үзләре тыныч, матур яшәсәләр, безгә шул бик җиткән.

Илдус абый мин сорашкач та: «Үзең өчен генә сөйлим, яза күрмә, яме. Бу яшьтә игътибар үзәгендә булу уңайсыз бит», – дип, кат-кат кисәтте. Язмыйм дип вәгъдә бирмәдем. Чөнки мондый дөнья бәһасе торырлык әйбәт кешеләр турында язмый кала алмаслыгымны белә идем. Аннан килеп, педучилищены тәмамлаган меңнәрчә укучылары да бер рәхәтләнеп, хатирәләргә күмелеп утырсыннар әле.

Мөгаллимнәребезгә барлык укучылары исеменнән сәламәтлек, имин тормыш телим. Безне шатландырып, озын-озак яшәсеннәр дигән теләктә калам.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Яңа ел килә

Казан Кремлендә әтиләре мобилизацияләнгән балалар өчен Яңа ел чаралары башланды. Аларда Казан һәм республика районнарыннан барлыгы 2,2 меңнән артык бала катнашачак.

– Казан Кремлендәге Яңа ел чыршысының беренче кунаклары Ватаныбызны саклау буенча үз бурычларын үтәүче мобилизацияләнгән гражданнарның 1–4 нче сыйныфларда укучы балалары булу бик мөһим. Бүген чараларда 750дән артык бала катнашты. Без инде райондагы хезмәттәшләребездән рәхмәт сүзләре кабул итәбез. Балаларның да кәефе бик яхшы. Ерак районнардан килгән балалар Кремльне, музейларын һәм күргәзмәләрен беренче тапкыр күрә. Алар буенча экскурсияләр узачак, – дип сөйләде журналистларга Татарстанның мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов.

Мобилизацияләнгән татарстанлыларның балалары өч көн дәвамында төрле мәйданчыкларда Казан циркы һәм театр артистлары, аниматорлар катнашында Яңа ел тамашаларын караячак, күргәзмәләр, квестлар, Кыш бабай һәм Кар кызы оештырган уеннарда катнашачак.

– Яңа ел – балалар өчен иң тылсымлы, могҗизалы бәйрәм. Ул балалар күңелендә онытылмаслык хис-кичерешләр калдырсын өчен, бар көчебезне куябыз. Балаларның куануын, елмаюларын күрү – безнең өчен зур шатлык, – ди Ленар Хәкимҗанов.

Театраль тамашадан соң балаларны чыршы янындагы әйлән-бәйләнгә чакырдылар. Монда аларны Яңа ел символлары – аждаһа, елан, юлбарыс һәм башка хайваннар көтә иде. Әйлән-бәйләндә бәйрәмнең иң көтеп алган, кадерле кунаклары – Кыш бабай, Кар кызы һәм Кар бабай да катнашты. Балалар, алар белән бергә чыршы тирәли әйләнеп, жыр башкарды.

Ләйсән САФИНА


«Татар-информ»

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

КЫШ БАБАЙ МАҖАРАЛАРЫ

Кыш бабай булуның иң бәхетле мизгеле – балаларның ышаныч тулы күзләрен күрүдер. Һәм шулай ук иң куркынычы да – шул балаларның күзләрендә ышаныч булмавын күрү яисә ышанычларын акламау.

Урак өсте. Көнгә өчәр «утренник» уйныйбыз. Кич өйләргә йөрибез, аннан кайтып авабыз да иртүк чыгып чабабыз. «Карлыгач» балалар бакчасында булды бу хәл. Тәрбияче апалар алдан барысын да кабатлатып куйган. Бас дисәң, басалар, утыр дисәң, утыралар, биюгә дә сикереп кенә чыгалар. Армияң читтә торсын. Менә шушы энәсеннән җебенә кадәр төгәл итеп эшләнгән бәйрәм сценариенда Кыш бабайның да билгеле бер урыны бар. Ярый ла балалар «Кыш бабай!» дип өч тапкыр кычкырса... Ничек тә ишетеп чыгарсың. Ә бу сценарийда Кыш бабай үзе керергә тиеш. Балалар көтмәгән мәлдә. Сюрприз, янәсе. Тик минем өчен сюрприз иртәрәк башланды. Кыш бабайга киенер өчен махсус психолог бүлмәсен бирделәр. Уенчыклар белән тулган склад. Ишеге дә бит аның намус белән эшләнгән, калын тимердән. Киенгәндә күрмәсеннәр дип, ишекне бикләп җырлый-җырлый киендем, грим салдым, уеннар тәртибен карадым. Соңга калмыйм дип ишек тоткасын борган идем – юк! Бикле! Дөрес, үзем бикләгән идем, кермәсеннәр дип, әмма аның эләгеп каласын кем белсен? Борам-борам, ачылмый. Тегеләй дә, болай да җайлап карыйм. Шалтыраттым тәрбиячегә, тик ул бит анда Убырлы карчык булып, бүләкләр урлап йөри. Телефонын алырга вакыты юк. Бетте баш! Эчтән генә белгәннәремне укый башладым. Аллаһы Тәгалә ярдәм иттеме, әллә язмышмы, янәшәдән үтеп киткән бер тәрбияче, мине ишетеп, ишекне ачты. Рәхмәт әйттемме, юкмы – хәтерләмим, тамаша залына йөгердем. Сюрприз ясап, бәйрәмнең чак башына ук барып кермәдем. Соңрак башлаганнар икән. Коридордагы баскыч артына качтым. Балалар гына вакытыннан алда күрмәсен. Кире бүлмәмә керергә шүрләтә. Торам шулай баскычта сакалымны җайлап (укыган догаларымнан соң, бераз кыйшайганнар), Аю алдан чыкмасынмы? Башлангычта укучы баланы аю булып уйнарга чакырганнар икән. «Әй, Кыш бабай!» – дип кычкырмасынмы!

«Т-сс! – мин әйтәм. – Кил монда».

– Нишләп монда торасың, Кыш бабай? Әйдә кер, – ди бу миңа.

Ә вакыт җитмәгән әле.

– Юк, – мин әйтәм, – бераз көтик. Балалар кабатлаганча җырласыннар, биесеннәр, – мин әйтәм, мөмкин кадәр калынрак тавыш белән сөйләшергә тәләп. – Бигрәк матур итеп уйнадың да инде Аюны! – дип шаяртып алдым.

– Каян күрдең? – дип шаккатты Аю баласы.

– Мин барысын да күрәм бит, белмисеңмени?

– Ә ничек?

Сорау арты сорау китте. Ә мин исә Кыш бабай исеменә тап төшермәс өчен шыттырам гына. Үзем сөйлим, үзем шуңа шаккатам. Юкка гына олылар, бер ялган икенчесен ияртә, дип әйтмәгән. Чәчәм бу малайга.

– Боланнарың кайда? – ди.

– Мин 3 ак ат җигелгән чанада килдем, – дим горур гына.

– Ә таягың кайда?

– Таягым атларны саклый. Сезнең монда атларны куяр урын да юк икән...

– Әйе, парковка белән авыр шул, – дип олыларча көрсенеп куйды малай. – Кая куйдың соң?

– Котельный артында, – дим. Кем уйлаган баскычтагы тәрәзәнең нәкъ котельныйга карап торуын. Аю баласы тәрәзәгә атылды. – Мин бит аларны сихерләдем. Таягым аларны кеше күзенә күренмәслек итеп саклап тота.

– Шулаймы? – дип сынаулы караш ташлады Аю баласы.

– Чынлап, улым, юкса кешеләр атларымны алып китәләр. Бер елны таягымны үзем белән алып кереп киткән идем, атларымны көчкә штрафстоянкадан эзләп таптым.

Аю баласы шунда ук ышанып, тотлыга-тотлыга әтисе белән машиналарын эзләп йөргәнен сөйләде. Аннан зәңгәр туныма бәйләнде.

– Синең курткаларың ничәү? – мин әйтәм.

– Дүртәү, – ди. – Җәйге, көзге һәм ике кышкы. Берсе – кызыл спортивный, икенчесе – кара җитди.

– Минем туннарым да берничә. Кызыл, зәңгәр, яшел, шәмәхә. Сурәтләре белән дә аерылып торалар.

Тагын күпме ялганлаган булыр идем – билгесез. Ниһаять, сценарийда мин керәсе җир җитте. Гафу үтенеп, бәйрәмгә кереп кушылдым. Гадәттә, бәйрәмнән тирләп чыксам, монда инде бәйрәмгә лыч булып килеп кердем. Тиешенчә сүзләремне әйтеп сәламләдем дә, Убырлы карчык белән Албастыны бәйләп салдык. Шунда бер бала туктап: «Чыршы янмый!» – дип кычкырмасынмы? Юк, сценарий буенча түгел иде бу. Әле уйныйсы, ярышасы бар, Убыр белән Албастыны җиңәсе. Ярар, күрмәмешкә салышып булмый бит инде. Туктап: «Чыршы, чыршы, матур син, утларыңны кабыз син!» – дип бер кычкырдык, ике кычкырдык. Гадәттә, өченчесендә кабынырга тиеш. Ә безнекендә кабынмый. Дүрт, биш тапкыр кычкырдык. Инде бөтен әти-әниләрне дә куштык... Кычкырмаган бер кеше дә калмаган кебек. Шулай да калган икән. Тәртип буенча, Убыр белән Албастыны гафу иткәч, Убырлы, күрше бүлмәгә чыгып, розеткага тыгарга тиеш икән. Ә ул бичара, авызына тыгылган чүпрәген чыгара алмыйча, ике күзен тутырып миңа карап утыра.

Бетердек инде сценарийны. Аңлавыгызча, тылсымлы чыршы барысы да яхшы булгач кына яна икән. Убырлы белән Албастыны азат иткәч, кабынды бәйрәмебез безгә. Бүләкләр таратылды, фотоларга төшелде. Ышаныч тулы күзләр, рәхмәт әйтеп, әти-әниләре янына таралышты. Ә саубуллашып чыгып киткәндә, мине ишек төбендә Аю баласы көтеп тора иде...

Илфак ХАФИЗОВ

Яңа елда син...

- ...«Тимә! Яңа елга бит бу!» – дип, кухнядан кычкырасың.
- ...сезнең фатирга ялгышып кергән кешеләргә дә шат буласың.
- ...Кыш бабайга хат язып, аны ирең̧ә бирәсең.
- ...быелгы хаталар турында уйламыйча, яңаларын планлаштырасың.
- ...ирең белән караңгы бүлмәдә пыш-пыш киләсең, балалар бүләкләрне күрмәсеннәр, дип.
- ...дусларың белән чыршы янында берничә кадр ясыйсың да, кемнең телефоны сыйфатлырак төшерә икән, дип чагыштыра башлыйсың.
- ...узган елны тизрәк онытырга телисең.

Фотофакт

Узган елны теләчелеләр иң зур юлбарыс сыны ясаганнар иде. Быел ел символы – куян әвәләгәннәр. Биеклеге тугыз метрдан артык, озынлыгы унбер метрдан артык булган сын янында олысы да, кечесе дә фотога төшә, ди. Куян елы булганлыктан, һәр оешма янында, ял паркында куян сыннары каршы ала икән. Алар гадәти куян түгел – спортсмен куяннан алып, язучы, банкир, агрономга кадәр бар, имеш. Кыскасы, куяннар саны районда 1001 данәдән артып китәргә тиеш, ди.

ХУШ КИЛӘСЕН, 2023! ХУШ, 2022!

Сине берәрсе капчыкка тыгып куйса, курыкма, без сине Кыш бабайдан үзебезгә бүләк итеп сорадык.

* * *

Яңа ел төнендә интернетта утырма. Чөнки анда күңелсезләнеп утырган кешеләр сине дә күңелсезләнеп утыра дип уйларга мөмкин.

* * *

Елның иң кыска көне – 1 гыйнвар. Син уянасың, ә урамда инде караңгы.

* * *

Яңа елга кадәр нибары алга таба ничек яшәргә икәнлегең аңлыйсы гына калды.

* * *

Көне килеп җиткәч, чират тормас өчен, Яңа елга ризыкларны берничә көн алдан алырга кирәк, дип уйлады бөтен шәһәр халкы һәм кибетләргә агылды.

* * *

– Әни, миңа Яңа елга эт алыгыз әле?
– Нинди эт сиңа тагын? Нормальный ризык аша!

* * *

Киләсе елга бәяләре төшәчәк тауар билгеле булды: быел сатылып бетмәгән чыршылар.

* * *

Яңа ел алдыннан кирәкми торган әйберләрне өйдән чыгарып аталар. Шуңа күрә ел ахырында хатынымның күзенә бик күренмәскә тырышам.

Фотомәзәк

Бик тиздән әлеге бәйрәм кошы үзенең канатларын җәячәк!

Рафис Атаказ Яңа елны һәрвакыт ялгызы каршылый

ӘЛЕК ЛЕНИН БАБАЙ ЯНЫНДА БӘЙРӘМ ИТКӘН

Яңа елга кем ничек әзерләнә. Берәүләр бу датага бөтенләй игътибар бирми, икенчеләр бер ай алдан затлы рестораннарда урын юнәтә, өченчеләр өчен бу – өйдә гаилә белән үткәрелә торган бәйрәм. Рафис Атаказ атлы популяр блогер дүрт ел рәттән Яңа елны бер ялгызы каршылый икән. Быел да шулай итмәкче. Бу хәлне ишеткәч, күзләремә яшьләр килде. Рафис Атаказның классташларын сагынып елаган роликтагы сыман. Хәтерлисездер: әлеге блогер нәкъ шул вируслы видеосы белән популяр булып киткән иде. Иртәрәк елаганмын, Атаказга Яңа елны шушылай ялгызы каршылау үзенә ошый икән. «Рәхәт! Зур компанияләр белән җыеласым килми. Һәр кешенең – үз тәртибе, ә мин үз көемчә яшәргә яратам. Яңа елдан соң бер-ике сәгать узгач, язып, шалтыратып котлый башлыйм», – дип сөйләде елак блогер «ВТ» «Хахаханә»сенә.

Рафисларда Яңа елда бүләк алышу гадәте юк икән. Аңа да бик бирмиләр, ул да әзерләми. Без үскәндә, андый әйбер юк иде, ди. Аның каравы бәйрәмнән соң күп тә үтми, 12 гыйнварда аның туган көне. Бүләкләр шунда була инде.

Берничә ел элек Казанга күченгән Атаказ элек Мәскәүдә яши иде. Моннан бер ун еллап элек Яңа елны Кызыл мәйданда каршылаганнар. Үзе әйтмешли, Ленин бабай янында. Ул чакта өстән гел яңгыр явып торган, бөтен кеше кулчатыр белән йөргән. «Ватаным Татарстан»ны укучы бөтен кешегә яңа 2023 елда бәхет теләп калам!» – диде Рафис.

P.S. Блогерның үзенчәлекле фамилиясенә игътибар итми мөмкинме соң? Әлбәттә, юк. (Узган «Хахаханә»дә язган Илдар Матуровка сәлам!) Күпләр уйлаганча, бу – тәхәллүс түгел. Рафисның чын фамилиясе – Атаказов! Туган ягы Чуашстанның Шыгырданында нинди генә фамилия булмас!

Бәйрәм ырым-шырымнары

- ✓ Яңа елны ничек каршыласаң, шулай үткәрерсең.
- ✓ Яңа ел төнендә салкын һәм әз генә кар явып торса – икмәк уңар. Карсыз һәм җылы булса – уңыш начар булыр.
- ✓ Бәйрәм кичендә берәр яңа әйбер кисәң, ел яхшы булыр.
- ✓ Яңа елның беренче көнендә үк авыр эш эшләгән кешенең елы да эштә генә үтәчәк.
- ✓ Бәйрәм табыны мул булса, ел әйләнәсендә дә ризыкка мохтаҗ булмаячаксыз.
- ✓ Елның беренче көнендә сатучы үзенең тәүге клиентына әйберне арзанга сатса, ел дәвамында аның сату эшләре гөрләп барачак.
- ✓ Киләсе елны бурычларга батып үткәрәсең килмәсә, Яңа ел алдыннан әҗәткә акча ала күрмә.
- ✓ Яңа ел алдыннан чүп чыгарырга ярамый. Өйдән бәрәкәт кача, диләр.
- ✓ Яңа ел төнендәге күк аяз һәм йолдызлы булса, җиләк-җимеш һәм гөмбә уңар.

ВӘСВӘСӘЛЕ ФӘЛСӘФӘ

Тормышны чиста биттән башлау җиңел дә бит, әмма почеркны үзгәртү ай-һай авыр!

* * *

«Тормышны шундый итеп яшәргә кирәк: социаль челтәрләрдә утырырга бөтенләй дә вакытың калмасын!» – дип язды ул «ВКонтакте»дагы битендә.

* * *

Кәстрүлдә бәрәңгене онытсагыз, ул тизрәк пешәчәк.

* * *

Ә безнең авылда лайклар куймыйлар. Ошаган кызың бар икән – бакчасына тирес китер!

* * *

Ни өчен иртә белән телевизордан төрле авырулар, эштәге проблемалар, брак тауарлар, банк карталары белән алдаулар турында күрсәтүче тапшыру «Хәерле иртә!» дип атала?

* * *

Бу юлы килгән чирнең дуңгыз гриппы икәнен мин, өйдә ятып, 5 килога тазаргач кына аңладым.

Мач әйткән!

Фаина РАНЕВСКАЯ, рус актрисасы

Яңа ел ул – элеккеге иллюзияләр белән хушлашып, яңалары белән шатлану вакыты.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6692 данә
Гомуми тираж – 15344 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 391

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+